# Татарча сөйләшәбез
# Говорим по-татарски



Методик кулланма

6—7 яшь

# Татарча сөйләшәбез
# Говорим по-татарски

*(6–7 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү)*

Методик кулланма

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән*

Без инде хәзер зурлар • мәктәпкә илтә юллар •

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2012

УДК 372.016 : 811.512.145*00
ББК 74.102 : 74.268.1Тат-96
Т23

А в т о р л а р ы:
З. М. Зарипова, Р. Г. Кидрәчева, Л. Ә. Шәрипова, Р. С. Исаева,
Р. М. Алексеева, А. И. Камалова, А. Д. Камалова, В. Р. Ситдыйкова,
М. С. Нургалиева

Р е ц е н з е н т л а р ы:
С. М. Гаффарова, Н. М. Шириева

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Татарча сөйләшәбез (6–7 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү):**
Т23 методик кулланма / [авт. : З. М. Зарипова һ. б.]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 72 б.
ISBN 978-5-298-02338-2

Методик кулланмада мәктәпкә әзерлек төркемендәге рус телендә сөйләшүче балаларны татар теленә өйрәтүнең методик нигезләре һәм заманча технологияләре бирелә. Кулланма балалар бакчаларында сабыйларга татар телен өйрәтүче тәрбиячеләргә, әти-әниләргә тәкъдим ителә.

УДК 372.016 : 811.512.145*00
ББК 74.102 : 74.268.1Тат-96

ISBN 978-5-298-02338-2 © Татарстан китап нәшрияты, 2012

# «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР» ПРОЕКТЫНЫҢ ТЕМАТИК ПЛАНЫ
## (мәктәпкә әзерлек төркеме)

| Актив сүзләр | Сөйләм үрнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм |
|---|---|---|
| *син кем?* | | Аудиоязма № 1, 2 |
| *хәерле көн* | – Хәерле көн, Оля (Коля)!<br>– Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби)! | Аудиоязма № 3–5<br>Дәфтәрдә эш № 1<br><br>Мультфильм: «Мияу адашкан» |
| *тычкан* | | Аудиоязма № 6<br>Дәфтәрдә эш № 2 |
| *бу кем?* | – Бу – әни (әти, кыз, малай)?<br>– Әйе, әни (әти, кыз, малай, ...). | Аудиоязма № 7, 8<br>Дәфтәрдә эш № 3<br><br>Мультфильм: «Аю баласы дөнья белән таныша» |
| *бу нәрсә?* | – Бу – туп (курчак, машина).<br>– Нинди туп?<br>– Кечкенә (зур, матур, чиста, ...). | Аудиоязма № 9, 10<br>Дәфтәрдә эш № 4 |
| *нишли?*<br>*йоклый* | – Песи нишли?<br>– Песи йоклый. | Аудиоязма № 11 |
| *утыра* | – Әни нишли?<br>– Әни утыра. | Мультфильм: «Батыр Мияу һәм куркак Куянкай» |
| *ашый,*<br>*эчә* | – Коля нишли?<br>– Коля ашый (эчә). | Аудиоязма № 12<br>Дәфтәрдә эш № 5 |
| *нишлисең?*<br>*ашыйм,*<br>*эчәм* | – Мияу, нишлисең?<br>– Ашыйм.<br>– Акбай, нишлисең?<br>– Эчәм. | Аудиоязма № 13, 14<br><br>Мультфильм: «Тату гаилә» |
| *уйный,*<br>*уйныйм* | – Оля (Коля), нишлисең?<br>– Уйныйм. | Аудиоязма № 15 |
| *утырам* | | Аудиоязма № 16–18 |

| Актив сүзләр | Сөйләм үрнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм |
|---|---|---|
| | | Мультфильм: «Юмарт аю» |
| *барам, кая барасың?* | – Кая барасың?<br>– Кафега барам. | Аудиоязма № 19 |
| *син нишлисең?* | – Син нишлисең?<br>– Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклыйм). | Аудиоязма № 20<br>Дәфтәрдә эш № 6 |
| | | Мультфильм: «Кафега барабыз» |
| *сикер – сикерәм* | Туп, туп,<br>Матур туп.<br>Сикер-сикер,<br>Матур туп. | Дәфтәрдә эш № 7 |
| *сикерә, йөгерә, төлке* | Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә.<br>Песи сикерә (йөгерә).<br>Төлке сикерә (йөгерә). | Аудиоязма № 21–24 |
| | | Мультфильм: «Урманда күңелле уеннар» |
| *йөгер – йөгерәм* | – Йөгер! Син нишлисең?<br>– Мин йөгерәм. | Аудиоязма № 25<br>Дәфтәрдә эш № 8 |
| *чәкчәк, өчпочмак* | – Мин чәкчәк ашыйм.<br>– Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма № 26–29 |
| | | Мультфильм: «Көчлеләр, кыюлар, җитезләр» |
| *яшь* | – Сиңа ничә яшь?<br>– Алты яшь. | Аудиоязма № 30–32<br>Дәфтәрдә эш № 9 |
| *бүре, керпе* | – Мин – бүре. Мин зур, матур, чиста. | |
| | | Мультфильм: «Җәнлекләр спорт бәйрәмендә» |
| *әтәч, тавык* | Әтәч зур, матур.<br>Тавык кечкенә, матур. | Аудиоязма № 33–35 |
| *үрдәк* | – Син нәрсә?<br>– Мин – үрдәк. | Аудиоязма № 36, 37<br>Дәфтәрдә эш № 10 |
| | | Мультфильм: «Циркта» |

| Актив сүзләр | Сөйләм үрнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм |
|---|---|---|
| *чана*<br>*шуа* | Куян чана шуа. | Аудиоязма № 38, 39<br>Дәфтәрдә эш № 11 |
| *шуам* | Мин чана шуам. | Аудиоязма № 40, 41<br>Дәфтәрдә эш № 12 |
| | | Мультфильм: «Шаян кошлар» |
| *бие,*<br>*бии* | – Аю, әйдә, бие! | Аудиоязма № 42, 43 |
| *биим* | | Аудиоязма № 44<br>Дәфтәрдә эш № 13 |
| | | Мультфильм: «Урманда зур концерт» |
| *ак,*<br>*кара* | – Оля кызыл шар ярата?<br>– Юк.<br>– Оля яшел шар ярата?<br>– Әйе, мин яшел шар яратам. | Аудиоязма № 45–48<br>Дәфтәрдә эш № 14 |
| *җырла –*<br>*җырлыйм* | – Син нишлисең?<br>– Мин җырлыйм. | Аудиоязма № 49–51 |
| | – Җырлыйбыз. | Аудиоязма № 52 |
| | | Мультфильм: «Акбай туган көнгә барырга әзерләнә» |
| *зур*<br>*рәхмәт* | Зур рәхмәт. | Аудиоязма № 50, 51, 53, 54<br>Дәфтәрдә эш № 15 |
| | | Мультфильм: «Мияуның туган көне» |
| *китап*<br>*укый* | Кыз китап укый. | Аудиоязма № 55<br>Дәфтәрдә эш № 16 |
| *рәсем*<br>*ясыйм* | Рәсем ясыйм – алма ясыйм. Мәктәп. | Аудиоязма № 56–58<br>Дәфтәрдә эш № 17 |
| | | Мультфильм: «Урман китапханәсендә» |
| *укыйм* | – Кем укый?<br>– Мин укыйм. | Аудиоязма № 59–62<br>Дәфтәрдә эш № 18 |
| | | Мультфильм: «Уйный-уйный укыйбыз» |

| Актив сүзләр | Сөйләм үрнәге | Аудиоязма<br>Эш дәфтәре<br>Мультфильм |
|---|---|---|
| | | Аудиоязма № 63–67 |
| | Бик тәмле. | Аудиоязма № 68 |
| *дәфтәр* | – Бу нәрсә?<br>– Дәфтәр.<br>– Нинди дәфтәр?<br>– Зур (матур, кечкенә, чиста), ак (кара, кызыл, яшел, зәңгәр, сары) дәфтәр.<br>– Ничә дәфтәр?<br>– Алты (1–10) дәфтәр. | Аудиоязма № 69, 70<br>Дәфтәрдә эш № 19 |
| | | Мультфильм: «Урман мәктәбендә» |
| | Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши,<br>Теремкәйдә куян яши,<br>Теремкәйдә бүре яши,<br>Теремкәйдә төлке яши,<br>Теремкәйдә аю яши. –<br>Алар бик дус. | Аудиоязма № 71 |
| | | Мультфильм: «Теремкәй» |
| | – Кәҗә кая?<br>– Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата. | Аудиоязма № 72 |
| | | Мультфильм: «Кем нәрсә ярата?» |
| | – Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>– Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>– Мә, кәҗә, ботка аша.<br>– Юк, мин кәбестә яратам. Кәбестә тәмле. | Аудиоязма № 73 |
| | | Аудиоязма № 74–76<br>Дәфтәрдә эш № 20 |
| | | Аудиоязма № 77, 78 |

# БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР

**Максат:** Балаларның сөйләмен көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Бурычлар:**

1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, сөйләм күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләменә карата кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт әйтү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

<table>
<tr><th colspan="2">1 нче тема: ӘЙДӘГЕЗ, ТАНЫШАБЫЗ!<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): син кем?</th></tr>
<tr><th>Эшчәнлек барышы</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Әйдәгез, танышабыз!»<br>Тәрбияче. Исәнмесез, балалар!<br>Балалар. Исәнмесез!<br>Тәрбияче. Хотите узнать, как меня зовут, спросите по-татарски: «Син кем? Син – син, кем – кем. Син кем, син кем?»<br>Тәрбияче. Мин ... . Син кем?<br>Балалар. Мин – Оля (Коля).<br>Шул рәвешле тәрбияче һәр баладан сорый.<br>2. Уен ситуациясе: «Мияу кунакта»<br>Аудио (1 нче кисәк)<br>Ишек шакыган тавыш (озын пауза) ишетелә.<br>Тәрбияче. Син кем? Не отвечает. Кто же это? Дети, помогите мне. Наверное, он хочет, чтобы мы у него спросили все вместе.<br>Тәрбияче. Син кем?<br>Бергә. Син кем?<br>Тәрбияче. Молчат. Давайте спросим погромче. Син кем?</td><td>Уенчыклар: Мияу, курчак, туп.<br>Аудиоязма № 1, 2</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Бергә.** Син кем?<br>**Мияу.** Мин – песи. Мин – Мияу.<br>**Тәрбияче.** А-а, это наш друг Мияу! Давайте позовём его.<br>**Бергә.** Мияу, кил монда!<br>Ишек ачылган тавыш (*кыска пауза*) ишетелә.<br>**Мияу** (*керә*). Исәнмесез!<br>**Балалар.** Исәнме, Мияу! Хәлләр ничек?<br>**Мияу.** Әйбәт. (*Кыска пауза.*)<br>**Балалар.** Мияу, утыр.<br>**Мияу.** Рәхмәт.<br>**Тәрбияче.** Мияу хочет с вами познакомиться. Поиграем с мячом в игру: «Син кем?»<br>**3. Сүзле уен: «Син кем?»**<br>Балалар түгәрәктә басып торалар. Мияу, бер балага тупны биреп: «Мин – Мияу. Син кем?» – дип сорый. Балалар шул тәртиптә уенны дәвам итәләр.<br>**Бала.** Син кем?<br>**Оля.** Мин – Оля. (Мин – кыз.)<br>**4. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (2 нче кисәк)*<br>– Ребята, слушайте, как знакомятся Оля с Колей.<br>**Оля.** Исәнме!<br>**Коля.** Исәнме!<br>**Оля.** Син кем?<br>**Коля.** Мин – Коля. Син кем?<br>**Оля.** Мин – Оля.<br>**5. Диалог: «Син кем?»**<br>Аудиоязма үрнәгендә ике бала арасында диалог. | |
| 2 нче тема: **ХӘЕРЛЕ КӨН!**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *хәерле көн* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Акбай белән Мияу бездә кунакта»**<br>*Аудио (3 нче кисәк)*<br>Ишек шакыган тавыш (*озын пауза*) ишетелә. | Уенчыклар: Акбай, Мияу, телефоннар. |

<table>
<tr><td>
Бергә. Син кем?<br>
Акбай. Мин – эт, Акбай. Һау-һау!<br>
Мияу. Мин – песи, Мияу. Мияу-мияу!<br>
Бергә. Акбай, кил монда.<br>
Мияу, кил монда.<br>
Акбай, Мияу. Исәнмесез, балалар!<br>
Балалар. Исәнмесез, Акбай, Мияу!<br>
<br>
2. Уен ситуациясе: «Хәерле көн!»<br>
Тәрбияче. Ребята, а теперь пожелаем им доброго дня: «Добрый день! – Хәерле көн!»<br>
Бергә. Хәерле көн!<br>
Акбай, Мияу. Хәерле көн!<br>
Һәр бала Акбай белән Мияуга хәерле көн тели.<br>
Коля. Хәерле көн, Акбай!<br>
Акбай. Хәерле көн, Коля!<br>
Оля. Хәерле көн, Мияу!<br>
Мияу. Хәерле көн, Оля!<br>
<br>
3. Сүзле уен: «Хәерле көн!»<br>
Балалар түгәрәккә басалар, бер-берсенә хәерле көн телиләр.<br>
Саша. Хәерле көн, Маша!<br>
Маша. Хәерле көн, Саша!<br>
<br>
4. Үстерелешле диалог: «Телефоннан сөйләшәбез»<br>
Аудио (4 нче кисәк)<br>
Акбай. Алло. Исәнме, Мияу!<br>
Мияу. Алло. Син кем?<br>
Акбай. Мин – Акбай.<br>
Мияу. Исәнме, Акбай!<br>
Акбай. Хәерле көн, Мияу! Хәлләр ничек?<br>
Мияу. Әйбәт. Рәхмәт. Акбай, хәлләр ничек?<br>
Акбай. Әйбәт. Рәхмәт. Сау бул, Мияу!<br>
Мияу. Сау бул, Акбай!<br>
Шул үрнәктә балалар бер-берсе белән телефоннан сөйләшәләр.<br>
<br>
5. Аудиоязма тыңлау, җырлау<br>
Аудио (5 нче кисәк)<br>
Җыр: «Хәерле көн!»<br>
Хәерле көн, әти! Хәерле көн, бабай!<br>
Хәерле көн, әни! Хәерле көн, әби!<br>
<br>
6. Дәфтәрдә эш: 1 нче бирем. «Вежливые слова»
</td>
<td>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма<br>№ 3–5</td></tr>
</table>

3 нче тема: **МИЯУ АДАШКАН**

МУЛЬТФИЛЬМ: «МИЯУ АДАШКАН»

4 нче тема: **СИН КЕМ?**

**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *тычкан*

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
|---|---|
| **1. Уен ситуациясе: «Шалканны кемнәр тарткан?»**<br>**Тәрбияче.** Ребята, вы помните сказку про репку? Кто посадил и вырастил большую репку? – Кем?<br>**Бергә.** Бабай.<br>**Тәрбияче.** Кто помог вытащить репку? Назовите их по-татарски.<br>**Бергә.** Әби, кыз, эт, песи, тычкан – мышь.<br>*Тычкан* сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>**2. Сүзле уен: «Ватык телефон»**<br>Уенда *кечкенә тычкан, матур тычкан* сүзтезмәләре кулланыла.<br>**3. Дидактик уен: «Кем юк?»**<br>Уенда «Шалкан» әкияте өстәл театры персонажлары кулланыла.<br>**4. Сүзле уен: «Син кем?»**<br>*Аудио (6 нчы кисәк)*<br>**Тәрбияче.** Акбай и Мияу тоже хотят играть с нами. Они должны хорошо запомнить ваши имена. Давайте проверим. Акбай отвернётся, а вы по очереди будете подходить и здороваться с ним. Акбай будет угадывать, кто это.<br>**Мияу.** Исәнме, Акбай!<br>**Акбай.** Син кем? Оля?<br>**Мияу.** Юк, мин – Мияу.<br>Шул үрнәктә балалар Акбай белән уенны дәвам итәләр.<br>**5. Уен ситуациясе: «Без шалкан утыртабыз»**<br>Тәрбияче балаларга әти, әни, әби, бабай, кыз, малай, эт, песи, тычкан рольләрен бүлеп бирә, битлекләр тарата.<br>**Тәрбияче.** Мы посадим свою репку. Она будет ещё больше. Чтобы её вытащить, нужно будет кого-то позвать. Давайте позовём и маму, и папу. Как позовём?<br>**Бергә.** Әти, кил монда. Әни, кил монда. | Уенчыклар: Акбай, Мияу.<br>«Шалкан» әкияте өстәл театры персонажлары: әби, бабай, кыз, малай, эт, песи, тычкан; әти, әни, әби, бабай, кыз, малай, эт, песи, тычкан битлекләре.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 6 |

| | |
|---|---|
| **6. Сүзле уен: «Җырлап әйт!»**<br>**Балалар** *(түгәрәктә җырлап әйләнәләр)*. Син кем?<br>**Битлек кигән бала** (*җырлап, уртага чыга*). Мин – бабай.<br>Уен барлык персонажлар (әби, эти, әни, кыз, малай, эт, песи, тычкан) белән шулай дәвам итә.<br>**7. Дәфтәрдә эш: 2 нче бирем. Сказка «Репка»** | |
| 5 нче тема: **«ШАЛКАН» ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *бу кем?* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Сүзле уен: «Бу кем?»**<br>Акбай белән Мияу эти, әни, кыз, малай, әби, бабай, тычкан рәсемнәрен алып киләләр.<br>**Мияу** (*бер рәсемне күрсәтеп*). Бу кем?<br>**Бергә.** Бу – әни (эти, кыз, малай, әби, бабай, тычкан).<br>**2. Дидактик уен: «Бу кем?»**<br>*Аудио (7 нче кисәк)*<br>Уенда «Шалкан» әкияте (үзебез уйлап чыгарган әкият) персонажлары рәсемнәре яки уенчыклары кулланыла. Мияу борылып баса, Акбай аңа сорау бирә.<br>**Акбай** (*эти рәсемен күрсәтеп*). Бу кем?<br>**Мияу.** Бу – эти.<br>**Акбай.** Әйе, эти. Бу кем? (*Бабай рәсемен күрсәтә.*)<br>**Мияу.** Бу – әни.<br>**Акбай.** Юк. Бу кем?<br>**Мияу.** Бу – кыз.<br>**Акбай.** Юк. Бу кем?<br>**Мияу.** Бу – бабай.<br>**Акбай.** Әйе, бу – бабай.<br>Шул үрнәктә уенны балалар дәвам итә.<br>**3. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (8 нче кисәк)*<br>– Ребята, послушайте, спросите: «Это кто? – Бу кем?»<br>– Исәнмесез! (*Әни тавышы, озын пауза.*)<br>– Бу кем? (*Балалар сорый.*)<br>– Бу – әни. (*Әни тавышы.*)<br>– Исәнмесез! (*Эти тавышы, озын пауза.*)<br>– Бу кем? (*Балалар сорый.*) | Уенчыклар: Акбай, Мияу.<br>Күрсәтмә рәсемнәр: эти, әни, кыз, малай, әби, бабай, тычкан; «Шалкан» әкияте персонажлары рәсемнәре яки уенчыклары.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 7, 8 |

| | |
|---|---|
| – Бу – эти. (*Эти тавышы.*)<br>– Хәерле көн, мыр-р-р... (*Песи тавышы, озын пауза.*)<br>– Бу кем? (*Балалар сорый.*)<br>– Бу – песи. (*Песи тавышы.*)<br>– Хәлләр ничек? Ырр-ырр... (*Эт тавышы, озын пауза.*)<br>– Бу кем? (*Балалар сорый.*)<br>– Бу – эт. (*Эт тавышы.*)<br>– Исәнмесез! Чи-чи-чи. (*Озын пауза.*)<br>– Бу кем? (*Балалар сорый.*)<br>– Бу – тычкан. (*Тычкан тавышы.*)<br>**4. «Шалкан» экиятен сәхнәләштерү**<br>Балаларга рольләр бүлеп бирелә.<br>– Син кем?<br>– Мин – бабай (әни, эти, кыз, малай, әби, тычкан).<br>**5. Дәфтәрдә эш: 3 нче бирем. «Это кто?»** | |
| 6 нчы тема: **АЮ БАЛАСЫ ДӨНЬЯ БЕЛӘН ТАНЫША**<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «АЮ БАЛАСЫ ДӨНЬЯ БЕЛӘН ТАНЫША» | |
| 7 нче тема: **БУ НӘРСӘ?**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *бу нәрсә?* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Мияуның уенчыклары»**<br>*Аудио (9 нчы кисәк)*<br>Өстәлгә төрле зурлыктагы уенчыклар (туп, куян, курчак, машина, аю, эт, песи, тычкан) куелган.<br>**Тәрбияче** (*бер уенчыкны кулына алып*). Ребята, мы с вами хорошо потрудились, вырастили большую репку. Молодцы! Теперь можно поиграть. Акбай и Мияу принесли нам игрушки. Давайте послушаем их разговор.<br>**Акбай.** Бу нәрсә?<br>**Мияу.** Бу – тычкан (туп, куян, курчак, машина, аю, эт, песи).<br>**Акбай.** Нинди тычкан?<br>**Мияу.** Кечкенә (зур) тычкан (туп, куян, курчак, машина, аю, эт, песи).<br>Уенны шул үрнәктә балалар дәвам итә. | Уенчыклар: Акбай, Мияу; төрле зурлыктагы туп, куян, курчак, машина, аю, эт, песи, тычкан уенчыклары. Эш дәфтәре. Аудиоязма № 9, 10 |

| | |
|---|---|
| **2. Дидактик уен: «Исемен әйтсәң бирәм»**<br>**Акбай** (*бер уенчыкны артына яшерә һәм Мияудан сорый*). Бу нәрсә?<br>**Мияу.** Бу – куян.<br>**Акбай.** Мә куян.<br>**Мияу.** Рәхмәт.<br>**Акбай.** Бу нәрсә?<br>**Коля.** Бу – аю.<br>**Акбай.** Мә аю.<br>**Коля.** Рәхмәт. Оля, бу нәрсә?<br>**Оля.** Бу – песи.<br>Уен шул үрнәктә башка балалар белән дәвам итә.<br>**3. Сюжетлы-рольле уен: «Уенчыклар кибетендә»**<br>*Аудио (10 нчы кисәк)*<br>Акбай белән Мияу сатучы һәм сатып алучы ролендә.<br>**Акбай.** Исәнме, Мияу!<br>**Мияу.** Исәнме, Акбай!<br>**Акбай.** Нәрсә кирәк?<br>**Мияу.** Туп кирәк.<br>**Акбай.** Нинди туп?<br>**Мияу.** Зур (кечкенә, матур) туп.<br>**Акбай.** Мә зур (кечкенә), матур туп.<br>**Мияу.** Рәхмәт. Сау бул, Акбай!<br>**Акбай.** Сау бул, Мияу!<br>**4. Җырлы-сүзле күнегү: «Бу нәрсә?»**<br>**Тәрбияче.** А теперь каждый сочините про свою игрушку песню.<br>**Тәрбияче һәм балалар** (*җырлап*).<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә?<br>– Бу – куян, бу – куян.<br>– Әйе, әйе, бу – куян,<br>Зур куян, матур куян.<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә?<br>– Бу – песи, бу – песи.<br>– Әйе, әйе, бу – песи,<br>Зур песи, матур песи.<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә?<br>– Бу – курчак, бу – курчак.<br>– Әйе, әйе, бу – курчак,<br>Зур курчак, матур курчак.<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә? | |

<table>
<tr><td>– Бу – машина, бу – машина.<br>– Әйе, әйе, машина,<br>Зур машина, матур машина.<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә?<br>– Бу – туп, бу – туп.<br>– Әйе, әйе, бу – туп,<br>Зур туп, матур туп.<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә?<br>– Бу – аю, бу – аю.<br>– Әйе, әйе, бу – аю,<br>Зур аю, матур аю.<br>– Бу нәрсә? Бу нәрсә?<br>– Бу – эт, бу – эт.<br>– Әйе, әйе, бу – эт,<br>Зур эт, матур эт.<br><br>5. Дәфтәрдә эш: 4 нче бирем. «В магазине игрушек»</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">8 нче тема: КЕМ НИШЛИ?<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): нишли? йоклый, утыра</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Уенчыклар йоклый»<br>Бүлмәдә кечкенә һәм зур уенчыклар (аю, куян, курчак, эт, песи, тычкан) төрлесе төрле җирдә таралышып яталар.<br><br>Тәрбияче. Ребята, посмотрите, что здесь случилось. Кто-то раскидал игрушки. А-а, это наши друзья Акбай и Мияу. Поиграли, устали и уснули. Пусть спят. Игрушки, наверное, тоже устали, давайте их уложим спать.<br><br>Һәр бала бер уенчыкны тирбәтеп йоклата.<br><br>Тәрбияче (балалардан сорый). Что делает мишка? – Аю нишли? (Пауза.)<br>Балалар. Мишка спит. – Аю йоклый.<br><br>Тәрбияче һәр баладан уенчыгы турында сорый.<br><br>Тәрбияче. Куян (курчак, эт, песи, тычкан) нишли?<br>Балалар (һәркайсы үз уенчыгын күрсәтеп). Йоклый.<br>«Йоклый» пиктограммасы белән таныштыру.</td><td>Кечкенә һәм зур уенчыклар: аю, куян, курчак, эт, песи, тычкан.<br>Күрсәтмә рәсемнәр: әни кул юа, эти йоклый, малай утыра, кыз битен юа, әби утыра, бабай йоклый.<br>«Йоклый», «утыра» пиктограммалары.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **2. Сүзле уен: «Кайтаваз» – «Эхо»**<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Куян нишли?<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Куян нишли?<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Куян йоклый.<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Куян йоклый.<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Аю нишли?<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Аю нишли?<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Аю йоклый.<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Аю йоклый.<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Тычкан нишли?<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Тычкан нишли?<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Тычкан йоклый.<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Тычкан йоклый.<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Песи нишли?<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Песи нишли?<br>**Тәрбияче** (*кычкырып*). Песи йоклый.<br>**Балалар** (*әкрен тавыш белән*). Песи йоклый.<br><br>**3. Сүзле уен: «Сорауга җавап бир»**<br>Балалар бер-берсеннән уенчыкның нишләвен сорыйлар.<br>**Оля.** Коля, куян нишли?<br>**Коля.** Куян йоклый. Аня, песи нишли?<br>**Аня.** Песи йоклый. Петя, аю нишли?<br>**Петя.** Аю йоклый.<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.<br><br>**4. Дидактик уен: «Кем нишли?»**<br>Тәрбияче, күрсәтмә рәсемнәр кулланып, балалардан: «Бу кем? Нишли?» – дип сорый.<br>**Тәрбияче.** Бу кем?<br>**Балалар.** Бу – әни (малай, кыз, бабай, әби, әти).<br>**Тәрбияче.** Әни нишли?<br>**Балалар.** Әни кул юа (йоклый).<br><br>**5. Уен ситуациясе: «Уенчыкларны йокыдан уят, урындыкка утырт»**<br>**Тәрбияче.** Игрушки поспали, отдохнули. Давайте их разбудим и посадим на стул. Скажите: «Садись. – Утыр». (*Куянны урындыкка утыртып.*) Что делает заяц? Куян нишли? Куян нишли? Куян утыра. Повторите: «Утыра».<br>**Балалар.** Утыра.<br>**Тәрбияче.** Куян утыра. | Аудиоязма № 11 |

| | |
|---|---|
| **Балалар.** Куян утыра.<br>**Тәрбияче.** Куян нишли?<br>**Балалар.** Куян нишли?<br>**Тәрбияче.** Куян утыра.<br>**Балалар.** Куян утыра.<br>**Тәрбияче.** Посадите свои игрушки на стул.<br>**Балалар** (*уенчыкларны урындыкларга утырталар һәм әйтәләр*). Куян (курчак, эт, песи, тычкан) утыра.<br>«Утыра» пиктограммасы белән таныштыру.<br>**6. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (11 нче кисәк): «Прослушай вопрос, найди соответствующую картинку»*<br>Балалар аудиоязмадан сорауны тыңлыйлар, кирәкле рәсемне табалар һәм җавап бирәләр.<br>– Әти нишли? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне табып*). Әти йоклый.<br>– Әйе, әти йоклый. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>– Әни нишли? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне табып*). Әни юа.<br>– Әйе, әни юа. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>– Кыз нишли? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне табып*). Кыз утыра.<br>– Әйе, кыз утыра. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>– Малай нишли? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне табып*). Малай йоклый.<br>– Әйе, малай йоклый. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>– Әби нишли? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне табып*). Әби юа.<br>– Әйе, әби юа. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>– Бабай нишли? *(Ир-ат тавышы, озын пауза.)*<br>**Балалар** (*рәсемне табып*). Бабай утыра.<br>– Әйе, бабай утыра. (*Хатын-кыз тавышы.*) | |
| 9 нчы тема: **БАТЫР МИЯУ БЕЛӘН КУРКАК КУЯНКАЙ**<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «БАТЫР МИЯУ БЕЛӘН КУРКАК КУЯНКАЙ» | |
| 10 нчы тема: **ДУСЛАРНЫ СЫЙЛЫЙБЫЗ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *ашый, эчә* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Сүзле уен: «Акбайны сыйлыйбыз»**<br>**Тәрбияче.** Акбай и Мияу пришли с прогулки, проголодались. Давайте их угостим. Посадим за стол, | Уенчыклар: Акбай, Мияу; ашамлык |

<table>
<tr><td>накормим и напоим. Позовите Акбая и Мияу за стол.<br>Балалар. Акбай (Мияу), кил монда, утыр.<br>Тәрбияче. Акбай (Мияу) нишли?<br>Балалар. Акбай утыра. Мияу утыра. Акбай, мә ипи, аша.<br>Акбай. Рәхмәт. Ипи тәмле.<br>Тәрбияче. Акбай кушает. – Акбай ашый.<br>Тәрбияче һәр баладан: «Акбай нишли?» – дип сорап чыга. Ашый сүзе һәр бала тарафыннан кабатлана. «Ашый» пиктограммасы белән таныштыру.<br>2. Сүзле уен: «Мияуны сыйлыйбыз»<br>Эчә сүзе Мияу белән шул үрнәктә өйрәтелә. «Эчә» пиктограммасы белән таныштыру.<br>3. Уен ситуациясе: «Иптәшеңне сыйла»<br>Оля. Коля, кил монда. Утыр.<br>Коля. Рәхмәт. (Утыра.)<br>Тәрбияче. Коля нишли?<br>Бергә. Коля утыра.<br>Оля. Коля, мә алма, аша (чәй эч).<br>Коля. Рәхмәт. Алма тәмле (чәй тәмле).<br>Тәрбияче. Коля нишли?<br>Бергә. Коля ашый (эчә).<br>Шул үрнәктә балалар уенны дәвам итәләр.<br>4. Дәфтәрдә эш: 5 нче бирем. «Кто что делает?»<br>Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.<br>5. Аудиоязма тыңлау<br>Аудио (12 нче кисәк)<br>Җыр: «Нишли?»<br>– Нишли? Нишли?<br>– Йоклый, йоклый.<br>– Нишли? Нишли?<br>– Утыра, утыра.<br>– Нишли? Нишли?<br>– Ашый, ашый.<br>– Нишли? Нишли?<br>– Эчә, эчә.</td><td>муляжлары.<br>«Ашый»,<br>«эчә» пикто-граммалары.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма<br>№ 12</td></tr>
<tr><td colspan="2">11 нче тема: НИШЛИСЕҢ?<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): нишлисең? эчәм, ашыйм</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Нишлисең?»<br>Акбай белән Мияу өстәл янында утыралар. Акбай ашый, Мияу эчә.</td><td>Уенчыклар:<br>Акбай, Мияу,<br>телефоннар;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| *Аудио (13 нче кисәк)*<br>**Тәрбияче.** Ребята, Акбай и Мияу угощаются. Мияу спрашивает: «Акбай, что делаешь? – Акбай, нишлисең?»<br>**Мияу.** Акбай, нишлисең?<br>**Акбай.** Кушаю. – Ашыйм, ашыйм. (*Хәрәкәт белән күрсәтә.*) Мияу, нишлисең?<br>**Мияу.** Пью. – Эчәм, эчәм. (*Хәрәкәт белән күрсәтә.*)<br>**Тәрбияче.** Спросите, что делает Акбай.<br>**Бергә.** Акбай, нишлисең?<br>**Акбай.** Ашыйм.<br>**Тәрбияче.** Спросите, что делает Мияу.<br>**Бергә.** Мияу, нишлисең?<br>**Мияу.** Эчәм.<br>**2. Сүзле уен: «Кайтаваз» – «Эхо»**<br>**Тәрбияче.** Нишлисең?<br>**Балалар.** Нишлисең?<br>**Тәрбияче.** Ашыйм.<br>**Балалар.** Ашыйм.<br>**Тәрбияче.** Аш ашыйм.<br>**Балалар.** Аш ашыйм.<br>**Тәрбияче.** Нишлисең?<br>**Балалар.** Нишлисең?<br>**Тәрбияче.** Эчәм.<br>**Балалар.** Эчәм.<br>**Тәрбияче.** Чәй эчәм.<br>**Балалар.** Чәй эчәм.<br>**3. Уен ситуациясе: «Без сыйланабыз»**<br>Балаларга ашамлык муляжлары таратыла. Балалар, парлашып, кара-каршы сөйләшәләр.<br>**Коля.** Оля, нишлисең?<br>**Оля.** Сөт эчәм. Коля, нишлисең?<br>**Коля.** Алма (ипи) ашыйм.<br>**4. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (14 нче кисәк)*<br>– Исәнме (хәерле көн), Оля! (*Малай тавышы.*)<br>– Исәнме (хәерле көн)! Син кем? (*Кыз тавышы.*)<br>– Мин – Коля. (*Малай тавышы.*)<br>– Хәлләр ничек, Коля? (*Кыз тавышы.*)<br>– Әйбәт. Хәлләр ничек, Оля? (*Малай тавышы.*)<br>– Әйбәт. (*Кыз тавышы.*)<br>– Оля, нишлисең? (*Малай тавышы.*)<br>– Алма ашыйм. Коля, нишлисең? (*Кыз тавышы.*) | ашамлык муляжлары.<br>Аудиоязма № 13, 14 |

<table>
<tr><td>– Чәй эчәм. (Малай тавышы.)<br>– Сау бул, Коля. (Кыз тавышы.)<br>– Сау бул, Оля. (Малай тавышы.)<br>5. Үстерелешле диалог: «Телефоннан сөйләшү»<br>Балалар бер-берсе белән телефоннан сөйләшәләр.<br>Петя. Алло. Исәнме (хәерле көн), Аня!<br>Аня. Исәнме (хәерле көн)! Син кем?<br>Петя. Мин – Петя.<br>Аня. Хәлләр ничек, Петя?<br>Петя. Әйбәт. Хәлләр ничек, Аня?<br>Аня. Әйбәт.<br>Петя. Аня, нишлисең?<br>Аня. Банан (ипи, алма) ашыйм. Петя, нишлисең?<br>Петя. Сөт (сок, чәй) эчәм.<br>Аня. Сау бул, Петя.<br>Петя. Сау бул, Аня.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">12 нче тема: ТАТУ ГАИЛӘ<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «ТАТУ ГАИЛӘ»</td></tr>
<tr><td colspan="2">13 нче тема: ӘЙДӘГЕЗ, УЙНЫЙБЫЗ!<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): уйный, уйныйм</td></tr>
<tr><th>Эшчәнлек барышы</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Мин уйныйм»<br>Һәр балага җитәрлек уенчыклар салынган тартма.<br>Тәрбияче. Сегодня к нам в гости пришёл зайчик. Он хочет играть. Давайте ему предложим мячик.<br>Балалар. Куян, мә туп. Уйна.<br>Куян. Рәхмәт.<br>Тәрбияче. Куян нишли? Играет – уйный, уйный. Уйный, уйный. Куян уйный.<br>Балалар. Уйный, уйный. Куян уйный.<br>«Уйный» пиктограммасы белән таныштыру.<br>Тәрбияче. Давайте спросим у зайчика, что он делает. Куян, нишлисең?<br>Куян. Играю – уйныйм. Уйныйм, уйныйм.<br>Тәрбияче. А теперь вместе спросим.<br>Бергә. Нишлисең?<br>Куян. Уйныйм.</td><td>Тартма (анда һәр балага җитәрлек санда уенчыклар); уенчык телефоннар. «Уйный» пиктограммасы. Аудиоязма № 15</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **2. Уен ситуациясе: «Бергәләп уйныйбыз»**<br>**Куян.** Оля, мә курчак, уйна. (*Оля уйный.*) Оля, нишлисең?<br>**Оля.** Уйныйм.<br>Уен һәр бала белән шул рәвешле дәвам итә.<br>**3. Ситуатив күнегү: «Уйный – уйныйм»**<br>1) **Тәрбияче.** Коля (Оля, ...) ты играешь. Как ты скажешь об этом?<br>**Коля.** Мин уйныйм.<br>2) **Тәрбияче.** Ребята, Коля играет. Как вы скажете об этом?<br>**Балалар.** Коля уйный.<br>Диалог һәр бала белән шул рәвешле дәвам итә.<br>**4. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (15 нче кисәк)*<br>– Исәнме, Оля! (*Малай тавышы.*)<br>– Исәнме, Коля! (*Кыз тавышы.*)<br>– Хәерле көн! (*Малай тавышы.*)<br>– Хәерле көн! (*Кыз тавышы.*)<br>– Хәлләр ничек? (*Малай тавышы.*)<br>– Әйбәт. Коля, хәлләр ничек? (*Кыз тавышы.*)<br>– Әйбәт. (*Малай тавышы.*)<br>– Коля, нишлисең? (*Кыз тавышы.*)<br>– Ботка ашыйм. Син нишлисең? (*Малай тавышы.*)<br>– Мин уйныйм. (*Кыз тавышы.*)<br>– Сау бул, Оля. (*Малай тавышы.*)<br>– Сау бул, Коля. (*Кыз тавышы.*)<br>**5. Үстерелешле диалог: «Телефоннан сөйләшү» («Нишлисең?»)**<br>*Уйныйм*, *ашыйм*, *эчәм* сүзләрен кулланып, балалар бер-берсе белән телефоннан сөйләшәләр.<br>**Коля.** Исәнме, Оля!<br>**Оля.** Исәнме, Коля!<br>**Коля.** Хәерле көн!<br>**Оля.** Хәерле көн!<br>**Коля.** Хәлләр ничек?<br>**Оля.** Әйбәт. Коля, хәлләр ничек?<br>**Коля.** Әйбәт.<br>**Оля.** Коля, нишлисең?<br>**Коля.** Ботка ашыйм. Син нишлисең?<br>**Оля.** Мин уйныйм.<br>**Коля.** Сау бул, Оля.<br>**Оля.** Сау бул, Коля. | |

14 нче тема: **КУНАК КИЛДЕ**
**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *утырам*

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
|---|---|
| **1. Уен ситуациясе: «Әби кунакка килә»**<br>*Аудио (16 нчы кисәк)*<br>Ишек шакыган тавыш (*озын пауза*) ишетелә.<br>**Бергә.** Кем анда?<br>**Әби.** Мин – әби.<br>**Бергә.** Әби, кил монда.<br>Ишек ачылган тавыш (*кыска пауза*) ишетелә.<br>Әби керә.<br>**Әби.** Исәнмесез, балалар!<br>**Бергә.** Исәнме, әби! Әби, хәлләр ничек?<br>**Әби.** Әйбәт, рәхмәт.<br>– Предложите бабушке стул. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Бергә.** Әби, утыр. (*Әби утыра.*)<br>– Әби, нишлисең? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Әби.** Сижу – утырам. Утырам.<br>**2. Ситуатив күнегү: «Әби утыра»**<br>Әби урындыкта утыра.<br>*Аудио (17 нче кисәк)*<br>– Бабушка, ты сидишь на стуле. Как скажешь, что сидишь? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Әби.** Утырам.<br>– Мияу, ты сидишь на стуле. Как скажешь, что сидишь? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Мияу.** Утырам.<br>– Акбай, ты сидишь на стуле. Как скажешь, что сидишь? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Акбай.** Утырам.<br>Шул үрнәктә *утырам* сүзе башка балалар белән кабатлана.<br>**3. Уен ситуациясе: «Әбине сыйла»**<br>*Аудио (18 нче кисәк)*<br>Мияу әбине чәй белән сыйлый.<br>1) **Мияу.** Әби, кил монда, утыр.<br>**Әби.** Рәхмәт.<br>**Мияу.** Әби, нишлисең?<br>**Әби.** Утырам. | Уенчыклар: Мияу; курчак театры атрибуты: әби; ашамлык атрибутлары.<br>Аудиоязма № 16–18 |

<table>
<tr><td>Мияу. Әби, мә чәй, эч.<br>Әби. Рәхмәт. Чәй эчәм, чәй тәмле.<br>2) Мияу. Коля, кил монда, утыр.<br>Коля. Рәхмәт.<br>Мияу. Коля, нишлисең?<br>Коля. Утырам.<br>Мияу. Коля, мә чәй, эч.<br>Коля. Рәхмәт. Чәй эчәм, чәй тәмле.<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.<br>4. Уен ситуациясе: «Чакыр– сыйла»<br>Коля.Оля, кил монда, утыр.<br>Оля. Рәхмәт.<br>Коля. Оля, нишлисең?<br>Оля. Утырам.<br>Коля. Оля, мә ипи, аша.<br>Оля. Рәхмәт. Ипи ашыйм, ипи тәмле.<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">15 нче тема: ЮМАРТ АЮ<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «ЮМАРТ АЮ»</td></tr>
<tr><td colspan="2">16 нчы тема: КАФЕГА БАРАБЫЗ<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): барам, кая барасың?</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Кафега барабыз»<br>Аудио (19 нчы кисәк)<br>– Акбай и Мияу встретились по пути в кафе. Слушайте, как они разговаривали друг с другом. (Хатын-кыз тавышы.)<br>Акбай. Исәнме, Мияу!<br>Мияу. Исәнме, Акбай! Хәлләр ничек?<br>Акбай. Әйбәт. Хәлләр ничек?<br>Мияу. Әйбәт.<br>Акбай. Мияу, куда идёшь?– Мияу, кая барасың?<br>Мияу. Иду в кафе.– Кафега барам. Акбай, кая барасың?<br>Акбай. Кафега барам.<br>2. Сүзле күнегү: «Кая барасың?»<br>Тәрбияче. Давайте спросим, куда идёт Акбай.<br>Балалар. Акбай, кая барасың?</td><td>Уенчыклар: Акбай, Мияу; кызыл, сары, яшел, зәңгәр шарлар; ашамлык муляжлары: чәй, кофе, сок, бәрәңге, пицца.<br>Аудиоязма № 19</td></tr>
</table>

**Акбай.** Кафега барам.
**Тәрбияче.** А теперь спросим, куда идёт Мияу.
**Балалар.** Мияу, кая барасың?
**Мияу.** Кафега барам.

Шул үрнәктә һәр бала Акбай белән Мияуга сорау бирә.

**3. Ситуатив күнегү**
1) **Тәрбияче.** Ты идёшь в кафе. Как ты скажешь об этом?
**Коля.** Кафега барам.
**Оля.** Кафега барам.
2) **Тәрбияче.** Твой друг (Коля) идёт в кафе. Как ты спросишь, куда он идёт? Коля, кая барасың?
**Коля.** Оля, кая барасың?
**Оля.** Коля, кая барасың?
**Коля.** Маша, кая барасың?

**4. Үстерелешле диалог**

Ике бала арасында диалог.

**Тәрбияче.** Мы тоже пойдём в кафе. Спросите друг у друга: «Куда идёшь? – Кая барасың?»
**Коля.** Оля, кая барасың?
**Оля.** Кафега барам. Коля, кая барасың?
**Коля.** Кафега барам. Маша, кая барасың?

Шул үрнәктә һәр бала бер-берсенә сорау бирә.

**5. Уен ситуациясе: «Шарны сорап ал»**
**Тәрбияче.** Чтобы в кафе было весело, возьмём с собой разноцветные шары (зәңгәр, сары, кызыл, яшел). Попросите у меня шары.
**Оля.** Шар бир әле.
**Тәрбияче.** Нинди шар?
**Оля.** Сары шар.
**Тәрбияче.** Мә сары шар.
**Оля.** Рәхмәт.

Шул үрнәктә һәр бала шар сорап ала.

**6. Уен ситуациясе: «Сиңа нәрсә кирәк?»**

Акбай сатучы ролендә. Ул кафеда чәй, кофе, сок, бәрәңге, пицца сата.

**Акбай.** Сиңа нәрсә кирәк?
**Бала.** Чәй (кофе, сок, пицца, бәрәңге) кирәк.
**Акбай.** Мә чәй.
**Бала.** Рәхмәт.

Һәр бала шул рәвешле үзенә ризык сорап ала.

17 нче тема: **БЕЗ КАФЕДА**

**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *син нишлисең?*

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
|---|---|
| **1. Ситуатив күнегү**<br>**Тәрбияче.** Ты сидишь в кафе, тебе звонит мама и спрашивает: «Что ты делаешь? – Син нишлисең?» Как ты ответишь, что:<br>1) Ты ешь картошку (пиццу)<br>(Мин бәрәңге (пицца) ашыйм);<br>2) Ты пьёшь чай (кофе, сок)<br>(Мин чәй (кофе, сок) эчәм).<br>Шул үрнәктә күнегү һәр бала белән кабатлана.<br><br>**2. Аудиоязма тыңлау: «Телефоннан сөйләшү»**<br>*Аудио (20 нче кисәк)*<br>– Слушайте, как Коля угощается в кафе. Из кафе Коля звонит Оле. (*Ир-ат тавышы.*)<br>**Коля.** Исәнме, Оля!<br>**Оля.** Исәнме, Коля!<br>**Коля.** Хәлләр ничек?<br>**Оля.** Әйбәт. Коля, син нишлисең?<br>**Коля.** Мин бәрәңге ашыйм.<br>**Оля.** Бәрәңге тәмле(ме)?<br>**Коля.** Әйе, бәрәңге тәмле. Оля, син нишлисең?<br>**Оля.** Мин уйныйм.<br>**Коля.** Сау бул, Оля.<br>**Оля.** Сау бул, Коля.<br>Аудиоязма үрнәгендә балалар арасында диалог төзелә.<br><br>**3. Дәфтәрдә эш: 6 нчы бирем. «Что ты делаешь?»**<br>Эшчәнлекне интерактив тактада оештырырга була. | Уенчык телефоннар; ашамлык муляжлары: чәй, кофе, сок, бәрәңге, пицца.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 20 |

18 нче тема. **КАФЕГА БАРАБЫЗ**

МУЛЬТФИЛЬМ: «КАФЕГА БАРАБЫЗ»

| 19 нчы тема: **КҮҢЕЛЛЕ УЕННАР**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *сикер, сикерәм* | |
|---|---|
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Бәйрәм»**<br>Кафедагы бәйрәмгә Бим исемле клоун килә.<br>**Бим.** Исәнмесез! Мин – клоун Бим.<br>**Балалар.** Исәнме, Бим!<br>**Бим.** Мой весёлый колпачок хочет с вами познакомиться. (*Баланың башына калпакны кидереп.*) Син кем?<br>**Оля.** Мин – Оля.<br>**Бим.** Син малай?<br>**Коля.** Мин – малай.<br>**Бим.** Син бабай?<br>**Маша.** Юк, мин – кыз.<br>Уен шулай дәвам итә.<br>**2. Уен ситуациясе: «Туп белән уйныйбыз»**<br>**Клоун** (*тупны күрсәтеп*). Бу нәрсә?<br>**Балалар.** Туп.<br>**Бим.** Туп нинди?<br>**Балалар.** Зур (кечкенә), матур, зәңгәр (сары, кызыл, яшел).<br>**Бим.** Ничә туп?<br>**Балалар.** Бер туп.<br>**Бим** (*балаларга таба тупларны тәгәрәтә*). Ничә туп?<br>**Балалар.** Ике (1–10) туп.<br>**Бим.** Давайте попросим мой мячик попрыгать.<br>**Балалар.** Туп, сикер!<br>**Бим.** Туп, туп,<br>Матур туп.<br>Сикер-сикер,<br>Матур туп.<br>Балалар шигырьне кабатлыйлар, үзләренең тупларын сикертәләр.<br>**Бим.** А сейчас мы сами превратимся в весёлых мячиков. | Клоун Бим, калпак, төрле төстәге туплар, шарлар.<br>Эш дәфтәре |

| | |
|---|---|
| **Бим.** Мин – туп. Мин сикерәм. Оля, син – туп. Сикер. Оля, нишлисең?<br>**Оля.** Мин сикерәм.<br>Шул үрнәктә клоун балалар белән уенны дәвам итә.<br>**3. Ситуатив күнегү**<br>1) **Тәрбияче.**Ты предлагаешь зайчику (другу) попрыгать. Как ты скажешь об этом?<br>**Коля.** Куян, сикер.<br>**Оля.** Коля, сикер.<br>2) **Тәрбияче.** Ты прыгаешь. Как скажешь, что прыгаешь?<br>**Коля.** Сикерәм. Мин сикерәм.<br>**Оля.** Сикерәм. Мин сикерәм.<br>**4. Уен-эстафета: «Кем тизрәк?»**<br>Балалар ике командага бүленә. Эстафета өчен һәр командага берәр шар бирелә. Бер бала, шарны тотып, билгеләнгән урынны сикереп әйләнеп килә, шарны икенче балага бирә.<br>**Бала.** Оля, мә шар, сикер.<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.<br>**5. Дәфтәрдә эш: 7 нче бирем. «Раскрась картинки»**<br>Клоун балаларны мактый, буяу өчен рәсемнәр тарата.<br>**Рәсемнәр:**<br>1. Куян сикерә.<br>2. Аю караватта йоклый.<br>3. Тычкан ашый.<br>4. Песи бит юа.<br>5. Малай сикерә.<br>6. Кыз уйный. | |
| 20 нче тема: **КҮҢЕЛЛЕ УЕННАР**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *сикерә, йөгерә, төлке* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Ситуатив күнегү: «Рәсем турында сөйлә»**<br>1) Балаларның үзләре буяган (клоун бүләк иткән) рәсемнәрен карау, эчтәлеген сөйләү.<br>*Аудио (21 нче кисәк)* | Уенчыклар: куян, песи, эт, аю, төлке. |

| | |
|---|---|
| 2) **Клоун**. У меня тоже есть рисунки, давайте их посмотрим. (*Рәсемне күрсәтеп.*) Зайчик прыгает. – Куян сикерә. Сикерә. Зайчик бежит. – Куян йөгерә.<br>Шул үрнәктә *йөгерә* сүзен өйрәтү.<br>**2. Сүзле уен: «Кайтаваз» – «Эхо»**<br>**Тәрбияче.** Сикерә.<br>**Балалар.** Сикерә.<br>**Тәрбияче.** Куян сикерә.<br>**Балалар.** Куян сикерә.<br>**Тәрбияче.** Туп сикерә.<br>**Балалар.** Туп сикерә.<br>**Тәрбияче.** Песи сикерә.<br>**Балалар.** Песи сикерә.<br>**Тәрбияче.** Эт сикерә.<br>**Балалар.** Эт сикерә.<br>Уенны шул ук үрнәктә *йөгерә* сүзе белән дәвам итү. «Сикерә», «йөгерә» пиктограммалары белән таныштыру.<br>**3. Дидактик уен: «Нәрсә юк?»**<br>Уен уенчыклар ярдәмендә оештырыла. *Төлке* сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>**4. Сүзле уен: «Ватык телефон»**<br>Уенда *матур төлке*, *зур төлке*, *төлке ашый* сүзтезмәләре кулланыла.<br>**5. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (22 нче кисәк)*: *«Прослушай, найди соответствующий рисунок»*<br>Балалар язманы тыңлыйлар һәм тиешле рәсемне табып күрсәтәләр.<br>– Бу – төлке. Төлке зур, матур. Төлке утыра. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)<br>– Бу – керпе. Керпе кечкенә, матур. Керпе уйный. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)<br>– Бу – аю. Аю зур, матур. Аю йоклый. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)<br>– Бу – песи. Песи кечкенә, матур. Песи сөт эчә. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)<br>– Бу – эт. Эт зур, матур. Эт ашый. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)<br>– Бу – кыз. Кыз кечкенә, матур. Кыз кул юа. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)<br>– Бу – куян. Куян кечкенә, матур. Куян сикерә. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*) | Балаларның үзләре буяган (клоун бүләк иткән) рәсемнәре; аю, куян, төлке, эт, песи, курчак, туп битлекләре. Сюжетлы рәсемнәр: төлке утыра; керпе уйный; аю йоклый; песи сөт эчә; эт ашый; кыз кул юа; куян сикерә; төлке йөгерә. «Сикерә», «йөгерә» пиктограммалары. Аудиоязма № 21–23, 24 |

– Бу – төлке. Төлке зур, матур. Төлке йөгерә. (*Озын пауза. Балалар рәсемне табып күрсәтәләр.*)

**6. Сюжетлы рәсемнәр турында балалар арасында диалог**

**Коля.** Бу нәрсә?
**Оля.** Бу – төлке.
**Коля.** Төлке нинди?
**Оля.** Төлке зур, матур.
**Коля.** Төлке нишли?
**Оля.** Төлке утыра.

Шул рәвешле башка балалар белән дә диалог төзелә.

**7. Үстерелешле диалог**

Балалар арасында диалог. Балалар үзләренә битлекләр сайлап алалар.

**Тәрбияче** (*аю ролендә*). Мин – аю. Мин – зур, матур аю. Мин йоклыйм. (*Хәрәкәт белән күрсәтә.*) Син кем? (*Куян битлеге кигән баладан сорый.*)
**Оля.** Мин – куян.
**Тәрбияче.** Син нинди куян?
**Оля.** Мин – кечкенә, матур куян.
**Тәрбияче.** Куян, нишлисең?
**Оля.** Сикерәм.

Диалог шул үрнәктә башка балалар арасында дәвам итә.

**8. Җырлы-биюле уен: «Әйдәгез, биибез!»**
*Аудио (23, 24 нче кисәк)*
1) Бар монда зур төлке.
Зур төлке, матур төлке. (*2 тапкыр*)
Төлке, төлке, кил әле,
Биеп-биеп кит әле. (*2 тапкыр*)
2) Бар монда зур аю,
Зур аю, матур аю. (*2 тапкыр*)
Аю, аю, кил әле,
Биеп-биеп кит әле. (*2 тапкыр*)
3) Бар кечкенә куян,
Кечкенә, матур куян. (*2 тапкыр*)
Куян, куян, кил әле,
Биеп-биеп кит әле. (*2 тапкыр*)
4) Бар кечкенә керпе,
Кечкенә, матур керпе. (*2 тапкыр*)
Керпе, керпе, кил әле,
Биеп-биеп кит әле. (*2 тапкыр*)

| 21 нче тема: **КҮҢЕЛЛЕ УЕННАР**<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «КҮҢЕЛЛЕ УЕННАР» | |
|---|---|
| 22 нче тема: **СПОРТ БӘЙРӘМЕНӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *йөгер, йөгерәм* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Диалог: «Син нишлисең?»**<br>*Аудио (25 нче кисәк)*<br>– Акбай и Мияу готовятся к спортивному празднику. Мияу, кая барасың? (*Ир-ат тавышы.*)<br>**Мияу.** Спорт бәйрәменә барам.<br>**Тәрбияче.** Акбай, кая барасың?<br>**Акбай.** Спорт бәйрәменә барам.<br>**Мияу.** Акбай, сикер! (*Акбай сикерә.*) Акбай, син нишлисең?<br>**Акбай.** Мин сикерәм. Мияу, беги! – Мияу, йөгер! Мияу, йөгер! (*Мияу йөгерә.*) Мияу, син нишлисең?<br>**Мияу.** Я бегу. – Мин йөгерәм. Йөгерәм.<br>Акбай яки Мияу балаларга команда бирә, диалогта шушы үрнәктә *йөгерәм* сүзе кабатлана.<br>**2. Уен ситуациясе: «Йөгерәм»**<br>Бәйрәмдә катнашу өчен, балалар ике командага бүленәләр. Акбай – «сикерүчеләр», Мияу «йөгерүчеләр» командасын җыя. Балаларга йөгерү, сикерү хәрәкәтләре белдергән эмблемалар таратыла.<br>**Акбай.** Син нишлисең?<br>**Оля.** Мин сикерәм.<br>**Мияу.** Син нишлисең?<br>**Коля.** Мин йөгерәм.<br>**3. Уен-эстафета: «Кем тизрәк?»**<br>Балалар ике командага бүленә. Эстафета өчен һәр командага берәр туп бирелә. Беренче бала, тупны тотып, билгеләнгән урынны йөгереп әйләнеп килә, тупны икенче балага бирә.<br>**Беренче бала.** Оля, мә туп, йөгер.<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.<br>**4. Ситуатив күнегү**<br>1) **Тәрбияче.** Ты предлагаешь зайчику (другу) побегать. Как ты скажешь об этом? | Эмблемалар, туплар.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма<br>№ 25 |

<table>
<tr><td>Коля. Куян, йөгер.<br>Оля. Коля, йөгер.<br>2) Тәрбияче. Ты бежишь. Как скажешь, что бежишь?<br>Коля. Йөгерәм. Мин йөгерәм.<br>Оля. Йөгерәм. Мин йөгерәм.<br>5. Дәфтәрдә эш: 8 нче бирем. «Что ты делаешь?»</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">23 нче тема: БӘЙРӘМГӘ БАРАБЫЗ<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): чәкчәк, өчпочмак</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Билет бир әле»<br>Акбай кассир ролендә.<br>Аудио (26 нчы кисәк)<br>– Акбай и Мияу собрались ехать в Казань. Покупают в кассе билеты. (Хатын-кыз тавышы.)<br>Мияу. Акбай, билет сат әле.<br>Акбай. Кая барасың?<br>Мияу. Казанга барам.<br>Акбай. Мә билет.<br>Мияу. Рәхмәт.<br>– Мы с вами тоже поедем в город Казань. Попросите у кассира билет. (Хатын-кыз тавышы.)<br>Шул үрнәктә балалар билет сорап алалар.<br>2. Аудиоязма тыңлау<br>Аудио (27 нче кисәк)<br>– Мы проезжаем заповедную зону. Тут обитают дикие животные, которых охраняют. (Пауза.) Ребята, скажите, кого вы видите. Что они делают? (Ир-ат тавышы.)<br>Аудиоязманы һәм балаларның җавабын тыңлау. Тәрбияче сюжетлы рәсемнәр күрсәтә, балалар түбәндәгечә җавап бирәләр.<br>– Бу – төлке. Төлке утыра.<br>– Бу – тычкан. Тычкан ашый.<br>– Бу – куян. Куян сикерә.<br>– Бу – аю. Аю йоклый.<br>3. Аудиоязма тыңлау<br>Аудио (28 нче кисәк)</td><td>Уенчыклар: Акбай, Мияу, билетлар.<br>Сюжетлы рәсемнәр: төлке утыра; тычкан ашый; куян сикерә; аю йоклый.<br>Аудиоязма № 26–29</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| – Остановка для отдыха. Здесь можно поесть и попить. (*Ир-ат тавышы.*)<br>**Акбай.** Мин өчпочмак ашыйм. Син нишлисең?<br>**Мияу.** Мин чәкчәк ашыйм.<br>Аудиоязма тыңлау, диалог төзү.<br>**Коля.** Мин өчпочмак ашыйм.<br>**Оля.** Мин бәрәңге ашыйм.<br>**Саша.** Мин сок эчәм.<br>**4. Аудиоязмадан җыр тыңлау, җырлау**<br>*Аудио (29 нчы кисәк)*<br>Мин барам, барам, барам,<br>Казанга барам, барам.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Казанга барам, барам. | |
| 24 нче тема: **КӨЧЛЕЛӘР, КЫЮЛАР, ҖИТЕЗЛӘР**<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «КӨЧЛЕЛӘР, КЫЮЛАР, ҖИТЕЗЛӘР» | |
| 25 нче тема: **КАЗАНДА СПОРТ БӘЙРӘМЕ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *яшь, **сиңа нинчә яшь**?* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Үстерелешле диалог: «Интервью бирү»**<br>*Аудио (30 нчы кисәк)*<br>Балаларда сикерү, йөгерү хәрәкәтен белдергән эмблемалар.<br>**Тәрбияче** (*корреспондент ролендә*). Исәнме! Мин – корреспондент. Син кем?<br>**Акбай.** Исәнмесез! Мин – Акбай.<br>**Тәрбияче.** Сиңа ничә яшь?<br>**Акбай.** Алты яшь.<br>**Тәрбияче.** Син нишлисең? (*Эмблемага күрсәтеп.*)<br>**Акбай.** Мин сикерәм (йөгерәм).<br>**Тәрбияче.** Рәхмәт.<br>Шул үрнәктә корреспондент Мияудан интервью ала.<br>**2. Үстерелешле уен: «Сөйләшәбез»**<br>Балалар бер-берсеннән интервью алалар.<br>**3. Уен ситуациясе: «Зарядка ясыйбыз»**<br>*Аудио (31, 32 нче кисәк)*<br>Балалар унга кадәр саныйлар, төрле гимнастик хәрәкәтләр ясыйлар. | Уенчыклар: Акбай, Мияу, микрофон, шар, туп (2 данә), бүләкләр. Йөгерү, сикерү хәрәкәтен белдергән эмблемалар. Эш дәфтәре. Аудиоязма № 30–32 |

| | |
|---|---|
| Әй нәниләр, нәниләр,<br>Ардык без, дип әйтмиләр.<br>Аякларын күтәреп,<br>Матур итеп атлыйлар.<br>Хәзер барабыз алга,<br>Егылмыйча, син атла!<br>1, 2, 3, 4, 5.<br>Хәзер барабыз артка,<br>Егылмыйча, син атла!<br>6, 7, 8, 9, 10.<br>Егылмыйча, син атла!<br>1, 2, 3, 4, 5.<br>Хәзер барабыз артка,<br>Егылмыйча, син атла!<br>6, 7, 8, 9, 10.<br>**4. Уен-эстафета: «Кем тизрәк?»**<br>Балалар ике командага бүленә. Эстафета өчен һәр командага берәр шар (туп) бирелә. Беренче бала, шарны (тупны) тотып, билгеләнгән урынны сикереп әйләнеп килә, шарны (тупны) икенче балага бирә.<br>**Беренче бала.** Оля, мә шар (туп), сикер!<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.<br>**5. Дәфтәрдә эш: 9 нчы бирем. «Расскажи о себе»**<br>**6. Сюрприз моменты**<br>Балаларга бүләкләр таратыла. | |
| 26 нчы тема: **БЕЗ ЦИРКТА**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *бүре, керпе* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Циркка барабыз»**<br>Балалар циркка барырга җыеналар, ләкин Мияу белән Акбай юк. Балалар хат табып алалар, укыйлар. Анда мондый сүзләр язылган: «Мы хотели пойти в цирк, а из цирка убежали зверята. Мы пошли их искать. Акбай и Мияу».<br>**Тәрбияче.** Мне кажется, что зверята прибежали к нам и где-то спрятались.<br>Тартмадан уенчыкларны алып күрсәтә.<br>**Тәрбияче** (*уенчыкларны алып*). Бу нәрсә?<br>**Балалар.** Бу – куян (аю, төлке, тычкан). | Уенчыклар: Акбай, Мияу, конвертта хат; тартмада куян, аю, төлке, тычкан уенчыклары |

<table>
<tr><td>Тәрбияче (бүре уенчыгын алып). Бу – бүре. Бу – бүре. Бүре.<br>Тәрбияче (керпе уенчыгын алып). Бу – керпе. Бу – керпе. Керпе.<br>Бүре, керпе сүзләре яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>2. Дидактик уен: «Нәрсә юк?»<br>Тәрбияче. Посмотрим ещё раз, кто убежал из цирка.<br>Балалар. Куян, аю, төлке, тычкан, керпе.<br>Тәрбияче бер уенчыкны яшерә.<br>Балалар. Бу бүре(ме)?<br>Тәрбияче. Юк.<br>Балалар. Бу төлке(ме)? (Аю, куян, керпе.)<br>Тәрбияче. Юк.<br>Балалар. Бу тычкан(мы)?<br>Тәрбияче. Әйе.<br>3. Уен ситуациясе: «Үзең турында сөйлә»<br>Балалар уенчыкларны алалар.<br>Тәрбияче. Давайте превратимся в зверей и расскажем, кто я, какой я, что делаю.<br>Бала. Мин – бүре. Мин зур, матур, чиста. Мин утырам. (Хәрәкәт белән күрсәтә.)<br>Уен шул рәвешле дәвам итә.<br>4. Ситуатив күнегү: «Йоклат»<br>Тәрбияче. Звери устали, уложите их спать.– Бүре йокла.<br>Шул үрнәктә күнегүне һәр бала үз уенчыгы белән кабатлый.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">27 нче тема: ҖӘНЛЕКЛӘР СПОРТ БӘЙРӘМЕНДӘ<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «ҖӘНЛЕКЛӘР СПОРТ БӘЙРӘМЕНДӘ»</td></tr>
<tr><td colspan="2">28 нче тема: БЕЗНЕҢ ДУСЛАР<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): тавык, әтәч</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Бу нәрсә?»<br>Аудио (33 нче кисәк)<br>– Ребята, к нам из цирка пришли домашние птицы. Давайте с ними познакомимся. (Хатын-кыз тавышы, кыска пауза.)</td><td>Уенчыклар: тавык, әтәч.<br>Курчак театры атрибутлары:</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Тәрбияче** (*этәчне күрсәтеп*). Әтәч. Әтәч. Әтәч.<br>**Бергә.** Әтәч. Әтәч. Әтәч.<br>**Тәрбияче** (*тавыкны күрсәтеп*). Тавык. Тавык. Тавык.<br>**Балалар.**Тавык. Тавык. Тавык.<br>*Әтәч, тавык* сүзләре яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>**Тәрбияче.** Әтәч нинди?<br>**Балалар.** Әтәч матур, зур.<br>**Тәрбияче.** Тавык нинди?<br>**Балалар.** Тавык матур, кечкенә.<br>**2. Сүзле уен: «Ватык телефон»**<br>Балаларга *этәч зур, тавык кечкенә* сүзтезмәләре әйтелә.<br>**3. Уен ситуациясе: «Әйткәнне үтә»**<br>Балаларга этәч, тавык битлекләре таратыла.<br>**Тәрбияче** (*һәр баладан сорый*). Син кем?<br>**Бала.** Мин – этәч (тавык).<br>**Тәрбияче.** Әтәч (тавык), кил монда. Син нинди этәч (тавык)?<br>**Бала.** Мин – зур (кечкенә), матур этәч (тавык).<br>**Тәрбияче.** Әтәч (тавык), сикер (аша, эч, йөгер, уйна, утыр).<br>Бала команданы үти.<br>**Тәрбияче.**Әтәч (тавык), син нишлисең?<br>**Бала.** Мин сикерәм (ашыйм, эчәм, йөгерәм, уйныйм, утырам).<br>**4. Ситуатив күнегү**<br>**Тәрбияче.** Петухи и курицы – птицы необычные, они умеют рассказывать о том, что делают. Петушок прыгает. Как он скажет об этом?<br>**Бала.** Мин – этәч (тавык). Мин сикерәм (йөгерәм, ашыйм, эчәм, утырам, уйныйм).<br>**5. Җырлы-биюле уен: «Әйдәгез, биибез!»**<br>*Аудио (34, 35 нче кисәк)*<br>1) Бар монда зур этәч,<br>Зур этәч, матур этәч.<br>Әтәч, этәч, кил әле,<br>Биеп, биеп кит әле. \| *2 тапкыр* | тавык, этәч; этәч, тавык битлекләре. Аудиоязма № 33–35 |

<table>
<tr><td>2) Бар кечкенә тавык,<br>Кечкенә, матур тавык.<br>Тавык, тавык, кил әле, | 2 тапкыр<br>Биеп, биеп кит әле.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">29 нчы тема: ҮРДӘК ДУСЛАРЫН ТАПТЫ<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): үрдәк</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Кунак килә»<br>Аудио (36 нчы кисәк)<br>Ишек шакыган тавыш (кыска пауза) ишетелә.<br>Балалар. Кем анда?<br>Үрдәк. Бак-бак, мин.<br>Балалар. Кил монда.<br>Ишек ачылган тавыш (кыска пауза) ишетелә.<br>Үрдәк. Исәнмесез!<br>Балалар. Исәнмесез! Син нәрсә?<br>Үрдәк. Мин – үрдәк. Мин – үрдәк. Үрдәк.<br>Үрдәк сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>2. Сүзле уен: «Ватык телефон»<br>Балаларга зур үрдәк, матур үрдәк сүзтезмәләре әйтелә.<br>3. Уен ситуациясе: «Дусларны сыйлыйбыз»<br>Аудио (37 нче кисәк)<br>Үрдәк. Бак-бак. Хозяин цирка ищет своих зверей и птиц. Он отправил меня за ними.<br>– Утка долго шла – проголодалась, давайте угостим её. Үрдәк, кил монда, утыр. Мә ботка, аша. (Хатын-кыз тавышы.)<br>Үрдәк. Бак-бак. Рәхмәт, ботка тәмле.<br>– Давайте позовём зверей, птиц и тоже угостим их. (Хатын-кыз тавышы.)<br>Үрдәк, тычкан, бүре, әтәч, тавык ролендәге балаларга битлекләр таратыла. Башка балалар аларны чакырып сыйлыйлар.<br>Оля. Бүре, кил монда, утыр. Мә ипи, аша.<br>Бүре. Рәхмәт, ипи тәмле.<br>Диалог шул үрнәктә дәвам итә.</td><td>Курчак театры атрибуты: үрдәк; үрдәк, тычкан, бүре, әтәч, тавык битлекләре. Эш дәфтәре. Аудиоязма № 36, 37</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>4. Ситуатив күнегү: «Макта!»<br>Тәрбияче. Ребята, хозяин цирка ждёт своих зверей и птиц. Но перед прощанием их надо похвалить. Как вы это сделаете? Оля, похвали утку.<br>Оля. Үрдәк, син матур, әйбәт, зур, чиста. Сау бул, үрдәк.<br>Балалар җәнлекләрне, кошларны мактыйлар, алар белән саубуллашалар.<br>5. Дәфтәрдә эш: 10 нчы бирем. «Циркта»</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">30 нчы тема: ЦИРКТА<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «ЦИРКТА»</td></tr>
<tr><td colspan="2">31 нче тема: АКБАЙ ЧАНА ШУА<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): чана, шуа</td></tr>
<tr><th>Эшчәнлек барышы</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Тауда»<br>Тәрбияче. Когда зверята возвращались в цирк, они увидели большую горку. На горке Акбай катается на санках.<br>Бергә. Исәнме, Акбай! Хәлләр ничек?<br>Акбай. Әйбәт.<br>Бергә (чанага күрсәтеп). Бу нәрсә?<br>Акбай. Санки – чана. Чана.<br>2. Аудиоязма тыңлау<br>Аудио (38 нче кисәк)<br>– Слушайте, как будет слово санки по-татарски. (Ир-ат тавышы, кыска пауза.)<br>– Чана. (Ир-ат тавышы, озын пауза. Тәрбияче куянның чанасын күрсәтә.)<br>– Чана. (Кыска пауза.) Повторите. (Кыска пауза.) Чана. (Ир-ат тавышы, озын пауза.)<br>– Чана. (Балалар кабатлый.)<br>– Чана. (Ир-ат тавышы, озын пауза.)<br>– Чана. (Балалар кабатлый.)<br>– Слушайте. (Кыска пауза.) Заяц катается на санках. (Ир-ат тавышы, кыска пауза.)<br>– Куян чана шуа. (Кыска пауза.) Куян чана шуа. (Ир-ат тавышы. Тәрбияче куянны чанасына утыртып шудыра.)</td><td>Уенчыклар: Акбай, чана.<br>Сюжетлы рәсемнәр: куян чана шуа; аю чана шуа; бүре чана шуа; керпе чана шуа; этәч чана шуа; төлке чана шуа; үрдәк чана шуа; тавык чана шуа.<br>«Чана шуа» пиктограммасы.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 38, 39</td></tr>
</table>

**3. Сүзле уен: «Нишли?»**

Уен сюжетлы рәсемнәр (куян (аю, бүре, керпе, әтәч, төлке, үрдәк, тавык) чана шуа) ярдәмендә оештырыла.

**Акбай.** Ребята, звери и птицы из цирка прислали вам свои фотографии. Я вам подарю фотографии, если вы правильно ответите на вопросы: «Бу нәрсә?», «Нишли?»
**Акбай.** Бу нәрсә? (Төлке, куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк.)
**Коля.** Бу – төлке (куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк).
**Акбай.** Төлке (куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк) нишли?
**Коля.** Төлке (куян, аю, бүре, керпе, әтәч, тавык, үрдәк) чана шуа.

Уен шул үрнәктә дәвам итә. «Чана шуа» пиктограммасы белән таныштыру.

**4. Үстерелешле диалог: «Бу нәрсә? Нишли?»**

Балалар арасында диалог.

**Коля** (*төлкегә күрсәтеп*). Бу нәрсә?
**Оля.** Бу – төлке.
**Коля.** Төлке нишли?
**Оля.**Төлке чана шуа.

Шул үрнәктә һәр бала сюжетлы рәсемнәр буенча диалог төзи.

**5. Аудиоязмадан җыр тыңлау, җырлау**
*Аудио (39 нчы кисәк)*
**Җыр: «Чана шуа»**
– Куян нишли?
– Чана шуа.
– Төлке нишли?
– Чана шуа.
– Бүре нишли?
– Чана шуа.
– Аю нишли?
– Чана шуа.

**6. Дәфтәрдә эш: 11 нче бирем. «На горке»**

| 32 нче тема: **ЧАНА ШУАМ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *шуам* | |
|---|---|
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Нишлисең?»**<br>Акбай белән Мияу, җырлый-җырлый, чана тартып керәләр.<br>*Аудио (40 нчы кисәк)*<br>– Мин – Акбай, мин – Акбай.<br>Зур Акбай, матур Акбай. (*Малай тавышы.*)<br>– Мин – Мияу, мин – Мияу.<br>Зур Мияу, матур Мияу. (*Кыз тавышы.*)<br>**2. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (41 нче кисәк)*<br>Акбай белән Мияу сөйләшә. Тәрбияче хәрәкәтләр белән күрсәтеп тора.<br>**Мияу.** Акбай, бу нәрсә? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Акбай.** Бу – чана. (*Ир-ат тавышы.*)<br>**Мияу.** Чана нинди? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Акбай.** Чана зур, кызыл. (*Ир-ат тавышы.*)<br>Чана шуган тавыш ишетелә.<br>**Мияу.** Акбай, нишлисең? (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Акбай.** Мин чана шуам. Мияу, кил монда. Утыр. (*Ир-ат тавышы.*)<br>**Мияу.** Мин чана шуам. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**3. Уен ситуациясе: «Шуа – шуам»**<br>**Тәрбияче.** Мияу и Акбай катаются на санках. Ребята, как вы скажете о том, что:<br>1) Акбай катается на санках<br>(Акбай чана шуа);<br>2) Мияу катается на санках<br>(Мияу чана шуа).<br>**Тәрбияче.** Акбай, ты катаешься на санках. Как ты скажешь об этом?<br>**Акбай.** Мин чана шуам.<br>**Тәрбияче.** Оля, ты катаешься на санках. Как ты скажешь об этом?<br>**Оля.** Мин чана шуам.<br>Шул рәвешле һәр бала сорауга җавап бирә. | Уенчыклар: Акбай, Мияу. Эш-хәрәкәтне белдергән (эчәм, ашыйм, утырам, уйныйм, барам, йөгерәм, сикерәм, йоклыйм, шуам) пиктограммалар. Эш дәфтәре. Аудиоязма № 40, 41 |

<table>
<tr><td>4. Үстерелешле диалог: «Син нишлисең?»<br>Диалог төзү. Балаларга схема-пиктограммалар (эчәм, ашыйм, утырам, уйныйм, барам, йөгерәм, сикерәм, йоклыйм, шуам) таратыла. Балалар арасында диалог.<br>Коля. Оля, син нишлисең?<br>Оля. Мин утырам. Син нишлисең?<br>Коля. Мин уйныйм.<br>Диалогта һәр бала катнаша.<br>5. Дәфтәрдә эш: 12 нче бирем. «Что ты делаешь?»<br>(Пиктограммалар кулланыла.)</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">33 нче тема: ШАЯН КОШЛАР<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «ШАЯН КОШЛАР»</td></tr>
<tr><td colspan="2">34 нче тема: ӘЙДӘ, БИЕ!<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): бие, бии; әйдә</td></tr>
<tr><th>Эшчәнлек барышы</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Бие!»<br>Аудио (42 нче кисәк)<br>«Зиләйлүк» татар халык көе яңгырый.<br>Тәрбияче. Ребята, послушайте, какая весёлая плясовая мелодия «Зиләйлүк». Так и хочется поплясать. Давайте вместе попросим: «Акбай, танцуй. – Акбай, бие. Мияу, танцуй. – Мияу, бие».<br>Бергә. Акбай, бие, бие! (Акбай бии.) Мияу, бие, бие! (Мияу бии.)<br>2. Татар халык уены: «Түбәтәй»<br>Аудио (43 нче кисәк)<br>«Зиләйлүк» татар халык көе яңгырый. Балалар түгәрәктә бию көенә бииләр, түбәтәйне кулдан-кулга йөртәләр. Музыка туктаганда, түбәтәй кем кулында калса, шул бала биергә тиеш була.<br>– Оля, бие, бие! (Оля уртага чыгып бии.)<br>– Коля, бие, бие! (Коля уртага чыгып бии.)<br>Уен шулай дәвам итә.<br>3. Ситуатив күнегү: «Нишли?»<br>Тәрбияче балаларга куян, аю, бүре, төлке, керпе, әтәч, тавык, үрдәк битлекләре өләшә.</td><td>Уенчыклар: Акбай, Мияу. Түбәтәй; куян, аю, бүре, төлке, керпе, әтәч, тавык, үрдәк битлекләре. «Бии» пиктограммасы. Аудиоязма № 42, 43</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Тәрбияче.** Ребята, представьте себе, что вы заводные игрушки.<br>«Заведите» игрушку и предложите прыгать.<br>1) **Бергә.** Куян, әйдә, сикер! (*Куян битлеге кигән бала сикерә.*)<br>**Тәрбияче.** Куян нишли?<br>**Бергә.** Куян сикерә.<br>2) **Бергә.** Аю, кил монда!<br>**Тәрбияче.** «Заведите» игрушку и предложите танцевать.<br>**Бергә.** Аю, әйдә, бие. (*Аю битлеге кигән бала бии.*)<br>**Тәрбияче.** Аю нишли?<br>**Бергә.** Аю бии.<br>Шул үрнәктә керпе, тычкан, бүре, төлке, әтәч, тавык, үрдәк битлекләре кигән балалар чакырыла. Аларга эш-хәрәкәтләрне (утыр, йөгер, йокла, ю, аша, уйна, эч) кабатларга кушыла. «Бии» пиктограммасы белән таныштыру.<br>**4. Ирекле бию: «Без биибез»**<br>**Тәрбияче.** Ребята, сегодня мы с вами очень хорошо занимались, весело играли, давайте вместе станцуем. Пригласите друг друга, предложите танцевать:<br>– Оля (Маша, Таня), кил, бие!<br>– Коля (Саша, Ваня), кил, бие!<br>Тәрбияче үрнәгендә балалар бер-берсен биергә чакыралар. Бергәләп бииләр. | |
| 35 нче тема**: БЕЗ БИИБЕЗ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *биим* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Без биибез»**<br>*Аудио (44 нче кисәк)*<br>Татар халык бию көе яңгырый. Акбай белән Мияу бииләр.<br>**Тәрбияче.** Акбай, син нишлисең? (*Акбай ишетми, һаман биеп тора.*)<br>– Ребята, Акбай не слышит. Давайте вместе спросим: «Акбай, син нишлисең?»<br>**Бергә.** Акбай, син нишлисең? | Уенчыклар: Акбай, Мияу. Хәрәкәтне белдергән (сикер, йөгер, уйна, утыр, бие) пиктограммалар; такта, мольберт. |

| | |
|---|---|
| **Акбай.** Мин биим. Мин биим. (*Акбай бии.*)<br>**Бергә.** Мияу, син нишлисең?<br>**Мияу.** Мин биим. Мин биим. (*Мияу бии.*)<br>**Акбай.** Оля, син нишлисең?<br>**Оля.** Мин утырам.<br>**Акбай.** Оля, әйдә, бие! (*Оля уртага чыга, бии.*)<br>**Мияу.** Коля, син нишлисең?<br>**Коля.** Мин утырам.<br>**Мияу.** Коля, әйдә, бие! (*Коля чыга, бии.*)<br>**Акбай.** Ребята, приглашайте друг друга плясать. Оля (Саша, Таня, Ваня, ...), кил, бие!<br>**Акбай.** Оля, син нишлисең?<br>**Оля.** Мин биим.<br>**Акбай.** Саша, син нишлисең?<br>**Саша.** Мин биим.<br><br>**2. Үстерелешле диалог: «Син нишлисең?»**<br>Балалар арасында диалог. Балаларда төрле хәрәкәтләрне белдергән (сикер, йөгер, уйна, утыр, бие) пиктограммалар.<br><br>**Коля.** Оля, син нишлисең?<br>**Оля** (*пиктограммага карап*). Мин сикерәм. Коля, син нишлисең?<br>**Коля** (*пиктограммага карап*). Мин биим. Саша, син нишлисең?<br>Уен шулай дәвам итә.<br><br>**3. Уен: «Нишли, әйт»**<br>Тактага яки мольбертка хәрәкәтне белдерә торган күрсәтмә рәсемнәр (куян сикерә, аю йоклый, песи сөт эчә, төлке бии, керпе йоклый, бүре йөгерә, эт ашый, тычкан чана шуа, бүре утыра) куелган. Бер бала рәсемне яшереп сорый.<br><br>1) **Коля.** Куян нишли?<br>**Балалар.** Куян бии?<br>**Коля.** Юк.<br>**Балалар.** Куян йоклый?<br>**Коля.** Юк.<br>**Балалар.** Куян сикерә?<br>**Коля.** Әйе, куян сикерә.<br>2) **Оля.** Төлке нишли?<br>**Балалар.** Төлке уйный?<br>**Оля.** Юк.<br>**Балалар.** Төлке йөгерә?<br>**Оля.** Юк. | Сюжетлы рәсемнәр: куян сикерә; аю йоклый; песи сөт эчә; төлке бии; керпе йоклый; бүре йөгерә; эт ашый; тычкан чана шуа; бүре утыра.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 44 |

<table>
<tr><td>Балалар. Төлке бии?<br>Оля. Әйе, төлке бии.<br>Уен шулай дәвам итә.<br>4. Дәфтәрдә эш: 13 нче бирем. «Кем нишли?»<br>(Пиктограммалар яисә сюжетлы рәсемнәр кулланыла.)</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">36 нчы тема: УРМАНДА ЗУР КОНЦЕРТ<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «УРМАНДА ЗУР КОНЦЕРТ»</td></tr>
<tr><td colspan="2">37 нче тема: МИЯУНЫҢ БҮЛМӘСЕН БИЗИБЕЗ<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): ак, кара</td></tr>
<tr><th>Эшчәнлек барышы</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Төсле шарлар сайла!»<br>Аудио (45 нче кисәк)<br>Акбай. Скоро у Мияу день рождения. Я не приготовил ей подарок. А знаете, почему? Зашёл в магазин, где продавались огромные воздушные шары. Но забыл, как называются цвета по-татарски, и стал показывать пальцем. Продавцы меня не поняли и не захотели со мной разговаривать. Чтобы такое не повторилось, помогите мне вспомнить название цветов по-татарски.<br>Балаларда төрле төстәге шар рәсемнәре: яшел, сары, кызыл, зәңгәр, ак, кара. Балалар, төсләрне әйтеп, тактага төрле төстәге шар рәсемнәре беркетәләр. Ә Акбай ак, кара шар рәсемнәре беркетә.<br>Акбай. Белый шар. – Ак шар. Чёрный шар. – Кара шар.<br>Ак, кара сүзләре яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>2. Дидактик уен: «Нинди шар юк?»<br>3. Сүзле уен: «Нинди шар яратам?»<br>Тәрбияче. Оля, кил монда.<br>Оля үзенә ошаган яшел шарны тактада күрсәтә.<br>Акбай. Оля кызыл шар ярата(мы)?<br>Оля. Юк.<br>Акбай. Оля яшел шар ярата(мы)?<br>Оля. Әйе, мин яшел шар яратам.<br>Уен шул рәвешле балалар арасында дәвам итә.</td><td>Уенчыклар: Акбай, төсле (кызыл, яшел, зәңгәр, сары, ак, кара) шарлар (1–10 га кадәр санда).<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 45–48</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **4. Уен ситуациясе: «Шар бир әле»**<br>**Акбай.** Подойдите и попросите у меня шар такого цвета, который вам нравится.<br>**Оля.** Акбай, ак шар бир әле.<br>**Акбай.** Мә ак шар.<br>**Оля.** Рәхмәт.<br>**Акбай.** Как скажешь, что тебе нравится белый шар?<br>**Оля.** Мин ак шар яратам.<br>Диалог балалар арасында дәвам итә.<br>**5. Уен: «Ничә шар?»**<br>Балалар шарларны (1–10 га кадәр) саныйлар.<br>**6. Уен ситуациясе: «Бүлмәне бизибез»**<br>Акбай ярдәмендә Мияуның бүлмәсен төсле шарлар белән бизиләр.<br>**7. Сүзле-хәрәкәтле уен: «Әгәр сиңа ошый икән, кабатла!»**<br>Акбай хәрәкәтләр күрсәтә. Балалар хәрәкәтләрне кабатлап күрсәтәләр, нинди хәрәкәт ясауларын әйтәләр.<br>*Аудио (46 нчы кисәк)*<br>**Акбай.** Если нравится тебе, то делай так. – Әгәр сиңа ошый икән, шулай эшлә. *(Бии.)*<br>**Балалар.** Акбай, син нишлисең?<br>**Акбай.** Мин биим (сикерәм, йөгерәм, туп уйныйм, утырам).<br>Шул үрнәктә уен дәвам итә.<br>**8. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (47, 48 нче кисәк)*<br>**Акбай.** Я думаю, что день рождения Мияу будет интересным, если мы для неё споём песню.<br>**Җыр: «Ак калач»**<br>Мияуның туган көненә<br>Без пешердек ак ипи.<br>Менә шундый зур ипи,<br>Менә шундый кечкенә.<br>Менә шундый тәмле,<br>Менә шундый баллы.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Әйе шул, ипи тәмле.<br>**9. Дәфтәрдә эш: 14 нче бирем. «Шары ко дню рождения»** | |

| 38 нче тема: **ТУГАН КӨНГӘ БҮЛӘК ӘЗЕРЛИБЕЗ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *җырла, җырлыйм* | |
|---|---|
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Үстерелешле диалог: «Кибет»**<br>**Акбай.** Чтобы купить подарки на день рождения Мияу, вспомним названия игрушек и вежливые слова.<br>Кибеттә төрле зурлыктагы һәм төстәге уенчыклар. Мәсәлән, ак һәм кара төстәге аю уенчыгы. Акбай сатучы ролендә. Акбай белән бала арасында түбәндәгечә сөйләшү була.<br>**Акбай.** Исәнме, Оля!<br>**Оля.** Исәнме, Акбай!<br>**Акбай.** Хәлләр ничек?<br>**Оля.** Әйбәт.<br>**Акбай.** Оля, нәрсә кирәк?<br>**Оля.** Куян кирәк.<br>**Акбай.** Нинди куян?<br>**Оля.** Ак (...), матур (...) куян.<br>**Акбай.** Ничә куян?<br>**Оля.** Ике куян.<br>**Акбай.** Мә ике куян.<br>**Оля.** Рәхмәт. Сау бул, Акбай!<br>**Акбай.** Сау бул!<br>Уен уенчыклар беткәнче дәвам итә.<br>**2. Үстерелешле уен: «Уенчыгың турында сөйлә»**<br>**Акбай.** Мы не просто подарим Мияу игрушки, а ещё и расскажем о них.<br>**Оля.** Бу – куян. Куян ак, матур, әйбәт. Куян сикерә.<br>**Коля.** Бу – песи. Песи сары. Песи сөт эчә. Песи утыра.<br>**Акбай.** Ребята, давайте все игрушки положим в красивую коробку. А когда пойдём на день рождения, подарим их Мияу.<br>**3. Уен: «Җырлыйм»**<br>*Аудио (49 нчы кисәк)*<br>**Акбай.** На день рождения Мияу я приготовил в подарок песню.<br>**Бергә.** Акбай, җырла.<br>**Акбай.** Я люблю петь! Я пою. – Мин җырлыйм. | Төрле зурлыктагы һәм төстәге уенчыклар.<br>Аудиоязма № 49–51 |

<table>
<tr><td>Акбай. Мин җырлыйм, җырлыйм (лә-лә-лә).<br>Бергә. Акбай, син нишлисең?<br>Акбай. Мин җырлыйм. А вы любите петь?<br>Тәрбияче. Оля, җырла.<br>Оля. Мин җырлыйм, җырлыйм (лә-лә-лә).<br>Җырла сүзе балалардан әйттерелә.<br>Тәрбияче. Коля, ты поёшь. Как ты скажешь об этом?<br>Коля. Мин җырлыйм.<br>4. Аудиоязма тыңлау, җырлау<br>Аудио (50, 51 нче кисәк)<br>1) Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм.<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм. | 2 тапкыр<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>2) Мин биим, биим, биим.<br>Мин матур биим, биим. | 2 тапкыр<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур биим, биим.<br>Акбай. Вот какую красивую песенку спели. Мияу обрадуется.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">39 нчы тема: АКБАЙ ТУГАН КӨНГӘ БАРЫРГА ӘЗЕРЛӘНӘ<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «АКБАЙ ТУГАН КӨНГӘ БАРЫРГА ӘЗЕРЛӘНӘ»</td></tr>
<tr><td colspan="2">40 нчы тема: МИЯУНЫҢ ТУГАН КӨНЕ<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): җырлыйбыз, зур рәхмәт</td></tr>
<tr><th>Эшчәнлек барышы</th><th>Җиһазлау</th></tr>
<tr><td>1. Уен ситуациясе: «Мияуда кунакта»<br>Акбай белән балалар Мияуга кунакка киләләр.<br>Бергә. Исәнме, Мияу!<br>Мияу. Исәнмесез, балалар!<br>Бергә. Хәлләр ничек, Мияу?<br>Мияу. Әйбәт. Рәхмәт.<br>Бергә. С днём рождения, Мияу! – Туган көнең белән, Мияу!</td><td>Уенчыклар: Акбай, Мияу.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 52</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Тәрбияче.** Давайте на день рождения Мияу споём песню «Каравай» – «Ак калач».<br>**Акбай.** Әйдәгез, җырлыйбыз.<br>**2. Аудиоязмага кушылып җырлау**<br>*Аудио (52 нче кисәк)*<br>**Җыр: «Ак калач»**<br>Мияуның туган көненә<br>Без пешердек ак ипи.<br>Менә шундый зур ипи,<br>Менә шундый кечкенә.<br>Менә шундый тәмле,<br>Менә шундый баллы.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Әйе шул, ипи тәмле.<br>**Мияу.** Зур рәхмәт.<br>**Акбай.** Ребята, Мияу говорит не просто спасибо, а «большое спасибо – зур рәхмәт».<br>**Мияу.** Зур рәхмәт.<br>**Акбай.** Попросите Мияу, чтобы она станцевала.<br>**Бергә.** Мияу, әйдә, бие.<br>Мияу татар халык бию көенә бии.<br>**Бергә.** Мияу матур бии.<br>**Мияу.** Зур рәхмәт.<br>**3. Үстерелешле диалог: «Минем бүләгем»**<br>Уенчыклар салынган тартма тора.<br>**Акбай.** Ребята, а теперь подарим игрушки Мияу. Сначала вспомним, кто какую игрушку купил.<br>Балалар тартмадан уенчыкларын табып алалар, алар турында сөйләп, Мияуга бүләк итәләр.<br>**Оля.** Бу – аю. Аю зур (матур, чиста, ак). Аю уйный (бии, җырлый). Мә, Мияу, аю.<br>**Мияу.** Зур рәхмәт.<br>Шул үрнәктә һәр бала уенчыгын Мияуга бүләк итә. Уйный, бии, утыра, сикерә, йоклый, шуа, йөгерә, ашый, эчә, җырлый дигәч, алар булып (өреп, кычкырып һ.б.), хәрәкәтләр белән күрсәтәләр. Мәсәлән, Мияу кычкыра: «Мияу-мияу», эт өрә: «Һау-һау».<br>**Мияу.** Зур рәхмәт. Приходите ещё. Сау булыгыз!<br>**Бергә.** Сау булыгыз!<br>**4. Дәфтәрдә эш: 15 нче бирем. «День рождения»** | |

| 41 нче тема: **ТУГАН КӨН ТАБЫНЫНДА**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *зур рәхмәт* | |
|---|---|
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Табышмакларга җавап тап»**<br>Уенны сюжетлы рәсемнәргә таянып үткәрергә була.<br>*Аудио (53 нче кисәк)*<br>– День рождения продолжается. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Мияу.** Я вам тоже приготовила сюрприз. Отгадайте мои загадки.<br>1) – Мин зур, матур, әйбәт. Мин йөгерәм, сикерәм, утырам, җырлыйм: «Тяф-тяф». Бу нәрсә? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>– Төлке. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>2) – Мин кара. Мин кечкенә, матур, әйбәт. Мин йөгерәм, сикерәм, биим, ашыйм, җырлыйм: «Чи-чи-чи». Бу нәрсә? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>– Тычкан. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>3) – Мин кызыл. Мин зур, матур, әйбәт. Мин ипи ашыйм, су эчәм, биим, җырлыйм: «Кикри-күк». Бу нәрсә? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>– Әтәч. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>4) – Мин ак. Мин кечкенә, матур, әйбәт. Мин ипи ашыйм, йөгерәм, җырлыйм: «Ко-ко-ко». Бу нәрсә? (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>– Тавык. (*Хатын-кыз тавышы.*)<br>**Мияу.** Зур рәхмәт!<br>**2. Уен ситуациясе: «Туган көн табынында»**<br>Уен муляжлар белән үткәрелә.<br>*Аудио (54 нче кисәк)*<br>**Мияу.** Әйдәгез, балалар, утырыгыз. Вы сидите за волшебным праздничным столом, будьте вежливы, угощайте друг друга.<br>**Мияу.** Нәрсә кирәк?<br>**Акбай.** Алма кирәк.<br>**Мияу.** Нинди алма? | Сюжетлы рәсемнәр: төлке, тычкан, әтәч, тавык.<br>Ашамлык муляжлары.<br>Аудиоязма № 50, 51, 53, 54 |

**Акбай.** Яшел (кызыл, сары), зур (кечкенә), тәмле алма.
**Мияу.** Мә яшел алма.
**Акбай.** Зур рәхмәт.
**Мияу.** Акбай, син нишлисең?
**Акбай.** Мин алма ашыйм.
**Мияу.** Алма тәмле(ме)?
**Акбай.** Әйе, алма тәмле. Мин алма яратам.

**3. Үстерелешле диалог: «Сыйланабыз»**

Алдагы эшчәнлек үрнәгендә балалар арасында диалог дәвам итә.

1) **Оля.** Коля, нәрсә кирәк?
**Коля.** Чәй (кофе, сок, сөт, бәрәңге, пицца) кирәк.
**Оля.** Мә чәй (кофе, сок, сөт, бәрәңге, пицца).
**Коля.** Чәй (кофе, сок, сөт, бәрәңге, пицца) тәмле. Зур рәхмәт.
2) **Оля.** Син нишлисең? (*Ашыйм*, *эчәм* сүзләре кабатлана.)
**Коля.** Мин чәкчәк (өчпочмак) ашыйм.
**Оля.** Чәкчәк (өчпочмак) тәмле(ме)?
**Коля.** Әйе, тәмле, баллы.
3) **Оля.** Коля, мә алма. (*Яратам* сүзе кабатлана.)
**Коля.** Мин алма яратам.
**Бергә** (*соңыннан*). Мияу, зур рәхмәт.

**4. Аудиоязма тыңлау, җырлау**
*Аудио (50, 51 нче кисәк)*
1) Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм. | *2 тапкыр*
Мин матур җырлыйм, җырлыйм. |
Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә.
Мин матур җырлыйм, җырлыйм.
2) Мин биим, биим, биим. | *2 тапкыр*
Мин матур биим, биим. |
Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә.
Мин матур биим, биим.

**5. Күмәк бию**

42 нче тема: **МИЯУНЫҢ ТУГАН КӨНЕ**

МУЛЬТФИЛЬМ: «МИЯУНЫҢ ТУГАН КӨНЕ»

## 43 нче тема: **КҮҢЕЛЛЕ СӘЯХӘТ**

**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *китап укый*

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
| --- | --- |
| **1. Уен ситуациясе: «Сәяхәткә әзерләнәбез»**<br>**Акбай.** Будем готовиться к путешествию в волшебную страну «Школа – Мәктәп». Мы с собой возьмём того, кто сможет ответить на вопросы Мияу. Будьте внимательны!<br>Мияу балаларга хәрәкәтне белдерә торган рәсемнәр күрсәтеп сорый.<br>**Мияу.** Оля, бу нәрсә?<br>**Оля.** Бу – куян.<br>**Мияу.** Куян нишли?<br>**Оля.** Куян сикерә (ашый, эчә, йөгерә, утыра, йоклый, бит юа, чана шуа, бии, җырлый).<br>**Мияу** (*китап укучы малай рәсемен күрсәтеп*). Малай нишли?<br>**Акбай.** Читает книгу. – Китап укый.<br>**Мияу.** Әйе, китап укый.<br>«Китап укый» пиктограммасы белән таныштыру.<br>**2. Аудиоязма тыңлау**<br>*Аудио (55 нче кисәк)*<br>Тәрбияче балаларга рәсемнәр күрсәтә.<br>– Малай китап укый. (*Пауза.*)<br>– Малай китап укый. (*Ир-ат тавышы. Тәрбияче рәсемне күрсәтә.*)<br>– Кыз китап укый. (*Пауза.*)<br>– Кыз китап укый. (*Хатын-кыз тавышы. Тәрбияче рәсемне күрсәтә.*)<br>– Куян китап укый. (*Пауза.*)<br>– Куян китап укый. (*Ир-ат тавышы. Тәрбияче рәсемне күрсәтә.*)<br>– Төлке китап укый. (*Пауза.*)<br>– Төлке китап укый. (*Хатын-кыз тавышы. Тәрбияче рәсемне күрсәтә.*)<br>*Китап* сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.<br>**3. Сүзле уен : «Нишли?»**<br>Мияу балаларга таратма рәсемнәр өләшә. | Эш-хәрәкәтләр сурәтләнгән рәсемнәр: куян (аю, песи, эт, төлке, тычкан) сикерә (ашый, эчә, йөгерә, утыра, йоклый, бит юа, чана шуа, бии, җырлый).<br>Күрсәтмә рәсемнәр: малай китап укый; кыз китап укый; куян китап укый; төлке китап укый.<br>«Укый» пиктограммасы.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 55 |

| | |
|---|---|
| **Мияу.** Кыз нишли?<br>**Коля.** Кыз китап укый.<br>**Мияу.**Куян нишли?<br>**Оля.** Куян китап укый.<br>**Мияу.** Төлке нишли?<br>**Саша.** Төлке китап укый.<br>**Мияу.** Молодцы! В путешествие берём всех ребят. Дорога дальняя. Чтобы в пути не было скучно, мы будем читать, писать, рисовать.<br>**4. Дәфтәрдә эш: 16 нчы бирем. «Волшебная школа»** | |
| 44 нче тема: **КҮҢЕЛЛЕ СӘЯХӘТ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *рәсем ясыйм, **мәктәп*** | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен ситуациясе: «Тылсымлы хат»**<br>*Аудио (56 нчы кисәк)*<br>**Мияу.** Перед нами лес. Ребята, смотрите, лесной компьютер, а в компьютере электронное письмо. Это письмо от волшебника. В нём написано, что волшебник рисует – рәсем ясый. Послушайте и повторите за ним. И если мы выполним задание, сможем идти дальше.<br>Акбай компьютерны «кабыза».<br>– Рәсем ясыйм. Алма ясыйм. (*Кыска пауза.*) Алма ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>– Рәсем ясыйм. Алма ясыйм.<br>– Рәсем ясыйм. Туп ясыйм. (*Кыска пауза.*) Туп ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>– Рәсем ясыйм. Туп ясыйм.<br>– Рәсем ясыйм. Шар ясыйм. (*Кыска пауза.*) Шар ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>– Рәсем ясыйм. Шар ясыйм.<br>– Рәсем ясыйм. Китап ясыйм. (*Кыска пауза.*) Китап ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>– Рәсем ясыйм. Китап ясыйм.<br>**2. Сүзле уен: «Мин рәсем ясыйм»**<br>Тәрбияче һавада алма рәсеме «ясап» күрсәтә. Балалар аудионы тыңлыйлар һәм анда әйтелгән предметның рәсемен куллары белән һавада «ясап» күрсәтәләр. Рәсем турында җөмлә төзиләр һәм кабатлыйлар. | Конвертта хат, уенчык компьютер.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 56–58 |

| | |
|---|---|
| *Аудио (57 нче кисәк)*<br>**Мияу.** Ребята, я тоже люблю рисовать. Я рисую яблоко. – Мин алма ясыйм.<br>– Мин рәсем ясыйм. Мин алма ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар*). Мин рәсем ясыйм. Мин алма ясыйм.<br>– Мин рәсем ясыйм. Мин туп ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар*). Мин рәсем ясыйм. Мин туп ясыйм.<br>– Мин рәсем ясыйм. Мин шар ясыйм. (*Ир-ат тавышы,озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар*). Мин рәсем ясыйм. Мин шар ясыйм.<br>– Мин рәсем ясыйм. Мин китап ясыйм. (*Ир-ат тавышы, озын пауза.*)<br>**Балалар** (*рәсемне «ясыйлар», җөмләне кабатлыйлар*). Мин рәсем ясыйм. Мин китап ясыйм.<br>**3. Сүзле уен: «Ватык телефон»**<br>Уен *рәсем ясыйм* сүзтезмәсе кулланып үткәрелә.<br>**4. Рәсем ясау: «Мияуга бүләк»**<br>**Балалар** (*үзләре теләгән рәсемнәрне ясыйлар һәм әйтәләр*). Мин рәсем ясыйм. Алма ясыйм. Мин рәсем ясыйм. Куян (...) ясыйм һ.б.<br>**5. Үстерелешле диалог: «Тылсымчыга шылтыратабыз»**<br>*Аудио (58 нче кисәк)*<br>**Мияу.** Ребята, давайте позвоним лесному волшебнику и скажем, что выполнили его задание. (*Телефоннан шылтырата.*) Хәерле көн!<br>**Тылсымчы.** Исәнмесез!<br>**Мияу.** Хәлләр ничек?<br>**Тылсымчы.** Әйбәт, син нишлисең?<br>**Мияу.** Мин рәсем ясыйм.<br>**Тылсымчы.** Нинди рәсем?<br>**Мияу.** Алма, туп, шар, китап.<br>**Тылсымчы.** Мәктәпкә килегез.– Приходите в школу.<br>**Мияу.** Мәктәпкә?<br>**Тылсымчы.** Әйе, мәктәпкә.<br>**Мияу.** Рәхмәт. Сау булыгыз!<br>**Тылсымчы.** Сау булыгыз!<br>**6. Дәфтәрдә эш: 17 нче бирем. «Я рисую»** | |

45 нче тема: **УРМАН КИТАПХАНӘСЕНДӘ**

МУЛЬТФИЛЬМ «УРМАН КИТАПХАНӘСЕНДӘ»

46 нчы тема: **КҮҢЕЛЛЕ СӘЯХӘТ**

**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *укыйм;* ***кем укый?***

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
|---|---|
| **1. Уен ситуациясе: «Мәктәпкә барам»**<br>*Аудио (59 нчы кисәк)*<br>**Мияу.** Ребята, лесной волшебник приглашает нас в волшебную страну, где говорят только на татарском языке. Возьмите телефон, расскажите друг другу, что вы поёте, танцуете, рисуете, читаете.<br>**Коля.** Исәнме, Оля!<br>**Оля.**Хәерле көн, Коля!<br>**Коля.** Хәлләр ничек?<br>**Оля.** Әйбәт.<br>**Коля.**Син нишлисең?<br>**Оля.** Мин рәсем ясыйм.<br>**Коля.** Нинди рәсем?<br>**Оля.** Матур китап. Син нишлисең?<br>**Коля.**Мин җырлыйм.<br>**Оля.**Сау бул, Коля.<br>**Коля.** Сау бул, Оля.<br>Шул үрнәктә балалар арасында диалог төзелә.<br>*Аудио (60 нчы кисәк)*<br>**Мияу.** Молодцы, ребята! Мы теперь точно попадём в волшебную страну «Школа – Мәктәп».<br>**2. Сүзле уен: «Кем укый?»**<br>*Аудио (61 нче кисәк)*<br>**Акбай.** Ребята, мы можем продолжить путь, ведь лесной волшебник пригласил нас в страну, которая называется «Школа – Мәктәп». Путешествие продолжается. Но что это? На нашем пути высокая гора, чтобы пройти гору, нужно прочитать пиктограммы. Если мы поймём, что на них написано, гора позволит нам продолжить дорогу.<br>**Мияу** (*пиктограмманы күрсәтеп*). Кем укый?<br>**Акбай.** Мин укыйм. (*Укый.*) Малай рәсем ясый.<br>**Мияу** (*пиктограмманы күрсәтеп*). Кем укый? | Телефоннар, конвертта хат.<br>Пиктограммалар: куян кишер ашый; песи сөт эчә; аю йоклый; эт йөгерә; кыз кул юа; бабай йоклый; төлке утыра; малай рәсем ясый; үрдәк җырлый; тычкан бии; бүре китап укый; әни бит юа; әти алма ашый; кыз чана шуа; куян сикерә.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 59–62 |

| | |
|---|---|
| **Оля.** Мин укыйм. (*Укый.*) Куян кишер ашый.<br>**Мияу** (*пиктограмманы күрсәтеп*). Кем укый?<br>**Коля.** Мин укыйм. (*Укый.*) Песи сөт эчә.<br>Шул үрнәктә һәр бала берәр пиктограмманы укып күрсәтә.<br>**Пиктограммалар:**<br>1. Куян кишер ашый.<br>2. Песи сөт эчә.<br>3. Аю йоклый.<br>4. Эт йөгерә.<br>5. Кыз кул юа.<br>6. Бабай йоклый.<br>7. Төлке утыра.<br>8. Малай рәсем ясый.<br>9. Үрдәк җырлый.<br>10. Тычкан бии.<br>11. Бүре китап укый.<br>12. Әни бит юа.<br>13. Әти алма ашый.<br>14. Кыз чана шуа.<br>15. Куян сикерә.<br>*Аудио (62 нче кисәк)*<br>**Мияу.**Трудное было задание, но мы справились. Дорога свободна. Нас впереди ждут удивительные приключения.<br>**3. Дәфтәрдә эш: 18 нче бирем. «Выполни задание»** | |
| 47 нче тема: **КҮҢЕЛЛЕ СӘЯХӘТ** | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Уен: «Командир»**<br>**Мияу.** Ребята, чтобы в дороге вы не устали, сделаем зарядку.<br>1) Өстәлдә төрле хәрәкәтләр сурәтләнгән пиктограммалар. Балалар ярымтүгәрәк ясап басалар. Бер бала, схема-рәсемне күрсәтеп: «Сикер!» – дип команда бирә, балалар сикерә. Уен шулай дәвам итә.<br>2) Балаларга төрле хәрәкәтләр сурәтләнгән пиктограммалар таратыла. Алар бер-берсенә команда бирәләр.<br>3) Бу уенны терәк рәсемнәрсез дә үткәрергә була. Балалар үзләре белгән командалар (сикер, йөгер, утыр, бие, җырла) кулланып уйныйлар. | Уенчыклар: Акбай, Мияу; чакыру билетлары. Пиктограммалар (сикер, йөгер, утыр, бие, җырла). Сюжетлы рәсемнәр: куян кишер ашый; песи сөт эчә; аю йоклый; эт |

| | |
|---|---|
| Бала, команданы үтәп: «Мин сикерәм (йөгерәм, утырам, биим, җырлыйм)», – ди.<br><br>**2. Аудиоязма тыңлау**<br>**Мияу.** Чтобы было веселее идти, послушаем песню.<br>*Аудио (63–65 нче кисәк)*<br>1) Мин барам, барам, барам,<br>Мәктәпкә барам, барам.<br>Китап, карандаш алам,<br>Мәктәпкә барам, барам.<br>2) Мин барам, барам, барам,<br>Мәктәпкә барам, барам.<br>Китап укыйм, рәсем ясыйм,<br>«4»ле һәм «5»ле алам.<br><br>**3. Үстерелешле уен: «Рәсемең турында сөйлә»**<br>*Аудио (66 нчы кисәк)*<br>**Мияу.** Ребята, вот мы с вами дошли до волшебной страны «Школа – Мәктәп». В школу зайдёт тот, кто скажет, что нарисовано на пригласительных билетах.<br>Билетларда сюжетлы рәсемнәр. Һәр бала үзенең рәсеме турында сөйли.<br>**Сюжетлы рәсемнәр:**<br>1. Бу – куян. Куян кишер ашый.<br>2. Бу – песи. Песи сөт эчә.<br>3. Бу – аю. Аю йоклый.<br>4. Бу – эт. Эт йөгерә.<br>5. Бу – кыз. Кыз кул юа.<br>6. Бу – бабай. Бабай йоклый.<br>7. Бу – төлке. Төлке утыра.<br>8. Бу – малай. Малай рәсем ясый.<br>9. Бу – үрдәк. Үрдәк җырлый.<br>10. Бу – тычкан. Тычкан бии.<br>11. Бу – бүре. Бүре китап укый.<br>12. Бу – әни. Әни бит юа.<br>13. Бу – әти. Әти алма ашый.<br>14. Бу – кыз. Кыз чана шуа.<br>15. Бу – куян. Куян сикерә.<br><br>**4. Уен ситуациясе: «Мәктәптә»**<br>Мәктәптә Мияу белән балаларны Акбай каршы ала.<br>*Аудио (67 нче кисәк)*<br>**Акбай.** Исәнмесез, балалар!<br>**Бергә.** Исәнме, Акбай! | йөгерә; кыз кул юа; бабай йоклый; төлке утыра; малай рәсем ясый; үрдәк җырлый; тычкан бии; бүре китап укый; әни бит юа; әти алма ашый; кыз чана шуа; куян сикерә.<br>Балалар санынча портфель макетлары, карандаш, ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом.<br>Аудиоязма № 63–67 |

<table>
<tr><td>Акбай. Хәлләр ничек?<br>Бергә. Әйбәт.<br>Акбай. Вы очень быстро прошли препятствия. Я вас поздравляю, возьмите подарки.<br>Акбай балаларга портфель макетлары тарата.<br>5. Уен ситуациясе: «Портфельне тутыр!»<br>Уен уку-язу әсбаплары ярдәмендә оештырыла. Диалог балаларның мөмкинлегенә карап, кыска яки үстерелешле итеп төзелә.<br>Акбай. Портфели пустые. Вам нужно подойти и вежливо попросить школьные принадлежности. (Карандаш бир әле.)<br>а) Оля. Акбай, карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом) бир әле.<br>Акбай. Мә карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом).<br>Оля. Рәхмәт.<br>ә) Коля. Акбай, карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом) бир әле.<br>Акбай. Нинди карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом)?<br>Коля. Кызыл карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом).<br>Акбай. Ничә карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом)?<br>Коля. Бер карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом).<br>Акбай. Мә карандаш (ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом).<br>Коля. Рәхмәт.</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">48 нче тема: УЙНЫЙ-УЙНЫЙ УКЫЙБЫЗ<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «УЙНЫЙ-УЙНЫЙ УКЫЙБЫЗ»</td></tr>
<tr><td colspan="2">49 нчы тема: МӘКТӘПТӘ<br>Актив сүзләр (сөйләм үрнәге): бик тәмле</td></tr>
<tr><td>Эшчәнлек барышы</td><td>Җиһазлау</td></tr>
<tr><td>1. Сүзле уен: «Портфельдә нәрсә бар?»<br>Мияу. Давайте вспомним, что мы положили в портфель. – Портфельдә нәрсә бар?<br>Балалар. Алма бар?</td><td>Уенчыклар: Акбай, Мияу; балалар санынча</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **Мияу.** Юк.<br>**Балалар.** Китап бар?<br>**Мияу.** Әйе, китап бар.<br>Уен шул үрнәктә барлык предметларны санап дәвам итә.<br>**2. Уен ситуациясе: «Ашханәдә»**<br>Өстәлдә ашамлык (аш, ботка, ипи, бәрәңге, сөт, су, сок, чәй, чәкчәк, өчпочмак) рәсемнәре. Мияу повар ролендә.<br>*Аудио (68 нче кисәк)*<br>**Мияу.** Нәрсә кирәк?<br>**Акбай.** Аш (ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, чәй, су, чәкчәк, өчпочмак) кирәк (бир әле).<br>**Мияу.** Мә аш (ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, чәй, су, чәкчәк, өчпочмак), аша (эч).<br>**Акбай.** Рәхмәт.<br>**Мияу.** Акбай, нишлисең?<br>**Акбай.** Мин аш (ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, чәй, су, чәкчәк, өчпочмак) ашыйм (эчәм).<br>**Мияу.** Аш нинди?<br>**Акбай.** Аш тәмле. Бик тәмле. Мин аш яратам.<br>Шул үрнәктә Мияу белән бала, аннан балалар бер-берсе белән диалог төзиләр.<br>**3. Күңел ачу, җырлау, бию, уеннар уйнау** | картон портфельләр, карандаш, ручка, китап, пенал, көндәлек, альбом. Ашамлык рәсемнәре: аш, ботка, ипи, бәрәңге, сөт, сок, су, чәй, чәкчәк, өчпочмак. Аудиоязма № 68 |
| 50 нче тема: **УКУ БҮЛМӘСЕ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:** *дәфтәр* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **1. Үстерелешле диалог: «Уку бүлмәсе белән танышабыз»**<br>Уен таратма рәсемнәр ярдәмендә оештырыла.<br>**Тәрбияче.** Мы пришли с вами в класс. Давайте посмотрим, что есть в классе.<br>**Мияу.** Бу нәрсә?<br>**Балалар.** Бу – өстәл (шкаф, урындык).<br>**Мияу.** Нинди өстәл (шкаф, урындык)?<br>**Балалар.** Зур (кечкенә) өстәл (шкаф, урындык).<br>**Мияу.** Ничә өстәл?<br>**Балалар.** Бер (1–10 га кадәр) өстәл (шкаф, урындык). | Фланелеграф. Күрсәтмә рәсемнәр: китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр. Ябыштыру өчен балалар санынча рәсемнәр: |

| | |
|---|---|
| **Мияу.** Өстәлдә нәрсә бар?<br>**Балалар.** Китап (дәфтәр, карандаш, пенал, ручка, альбом, клей, линейка).<br>Диалог шул үрнәктә балалар арасында оештырыла.<br>**2. Үстерелешле диалог: «Нәрсә, нинди, ничә?»**<br>Фланелеграфта китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр рәсемнәре.<br>*Аудио (69 нчы кисәк)*<br>**Акбай.** Ребята, продолжим путешествие по волшебной стране «Школа – Мәктәп».<br>**Диалог үрнәкләре:**<br>1) **Акбай.** Бу нәрсә?<br>**Балалар.** Китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал).<br>**Акбай.** Нинди китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал)?<br>**Балалар.** Зур (кечкенә), матур, чиста, ак (кара, кызыл, яшел, сары, зәңгәр) китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал).<br>**Акбай.** Ничә китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) бар?<br>**Балалар.** Биш (1–10 га кадәр) китап (альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) бар.<br>*Аудио (70 нче кисәк)*<br>2) **Акбай.** Бу нәрсә?<br>**Мияу.** Белмим.<br>**Акбай.** Бу – дәфтәр. Дәфтәр.<br>**Мияу.** Дәфтәр. Дәфтәр.<br>**Акбай.** Нинди дәфтәр?<br>**Мияу.** Чиста, матур, зур (кечкенә) дәфтәр.<br>**Акбай.** Ничә дәфтәр?<br>**Мияу.** Бер (1–10 га кадәр) дәфтәр.<br>3) **Акбай.** Оля, бу нәрсә?<br>**Оля.** Дәфтәр. Дәфтәр.<br>**Акбай.** Нинди дәфтәр?<br>**Оля.** Чиста, матур, яшел (зәңгәр, кызыл, сары) дәфтәр.<br>4) **Мияу.** Коля, бу нәрсә?<br>**Коля.** Дәфтәр. Дәфтәр.<br>**Мияу.** Нинди дәфтәр?<br>**Коля.** Дәфтәр зур (кечкенә), ак (сары, яшел, кызыл, зәңгәр, кара). | китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр.<br>Таратма рәсемнәр: төрле төстә, санда (1–10 га кадәр) шкаф, өстәл, урындык; клей.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма № 69, 70 |

5) **Оля.** Коля, бу нәрсә?
**Коля.** Дәфтәр. Дәфтәр.
**Оля.** Нинди дәфтәр?
**Коля.** Зур (кечкенә), матур, чиста, ак (кара, кызыл, яшел, сары, зәңгәр) дәфтәр.
**Оля.** Ничә дәфтәр?
**Коля.** Алты (1–10 га кадәр) дәфтәр.

*Дәфтәр* сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.

**3. Сүзле уен: «Нәрсә кирәк?»**
**Тәрбияче.** Оля, нәрсә кирәк?
**Оля.** Дәфтәр кирәк.
**Тәрбияче.** Мә дәфтәр, ал.
**Оля.** Рәхмәт.

Шул үрнәктә һәр бала тәрбиячедән эш дәфтәрен сорап ала. Өстәлдә уку-язу әсбаплары (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал, дәфтәр) рәсемнәре. Балалар тәрбиячедән алган рәсемнәрне дәфтәрләрендә ясалган портфельгә ябыштыралар.

**Тәрбияче.** Оля, нәрсә кирәк?
**Оля.** Дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк.
**Тәрбияче.** Нинди дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк?
**Оля.** Зур (кечкенә), яшел (сары, кызыл, ак, кара, зәңгәр) дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк.
**Тәрбияче.** Ничә дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк?
**Оля.** Өч (1–10 га кадәр) дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал) кирәк.
**Тәрбияче.** Мә өч (1–10 га кадәр) дәфтәр (китап, альбом, клей, линейка, ручка, карандаш, пенал).
**Оля.** Рәхмәт.

Һәр бала шул үрнәктә тәрбиячедән уку-язу әсбапларын сорап ала, дәфтәргә ябыштыра.

**4. Дәфтәрдә эш: 19 нчы бирем. «Что в портфеле?»**

## 51 нче тема: **УРМАН МӘКТӘБЕНДӘ**

МУЛЬТФИЛЬМ: «УРМАН МӘКТӘБЕНДӘ»

| 52 нче тема: **ӨСТӘЛ ТЕАТРЫ «ТЕРЕМКӘЙ»** | |
|---|---|
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **Өстәл театры: «Теремкәй» экияте**<br>*Аудио (71 нче кисәк)*<br>**Тәрбияче.** Сегодня я вам расскажу сказку «Теремок».<br>**Тәрбияче.**<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә кем яши? (*Ишек шакый.*) Юк, яшәми.<br>Теремкәйгә тычкан килә.<br>**Тычкан** (*ишек шакый*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши? (*Тавыш юк.*) Юк, яшәми. Мин яшим.<br>**Тәрбияче.**<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйгә куян килә.<br>**Куян** (*ишек шакый*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>**Тычкан.** Мин – тычкан. Син кем?<br>**Куян.** Мин – куян. Матур куян.<br>**Тычкан.** Әйдә, кил монда.<br>**Куян** (*керә*). Мин сикерәм. Әйдәгез, сикерәбез.<br>Балалар белән бергә сикерәләр.<br>**Тәрбияче.**<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши,<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйгә бүре килә.<br>**Бүре** (*ишек шакый*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>**Тычкан.** Мин – тычкан.<br>**Куян.** Мин – куян.<br>**Бергә.** Син кем?<br>**Бүре.** Мин – бүре. Мин – зур, кара бүре. | Өстәл театры атрибутлары: тычкан, куян, бүре, төлке, аю.<br>Аудиоязма № 71 |

**Бергә.** Әйдә, кил монда.
**Бүре** (*керә*). Мин йөгерәм. Әйдәгез, йөгерәбез.

Балалар белән бергә йөгерәләр.

**Тәрбияче.**
Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши,
Теремкәйдә куян яши,
Теремкәйдә бүре яши.

Теремкәйгә төлке килә.

**Төлке** (*ишек шакый*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан.** Мин – тычкан.
**Куян.** Мин – куян.
**Бүре.** Мин – бүре.
**Бергә.** Син кем?
**Төлке.** Мин – төлке. Мин – зур, матур төлке.
**Бергә.** Әйдә, кил монда.
**Төлке** (*керә*). Мин биим. Әйдәгез, биибез.

Музыка. Балалар белән бергә бииләр.

**Тәрбияче.**
Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, кечкенә.
Теремкәйдә тычкан яши,
Теремкәйдә куян яши,
Теремкәйдә бүре яши,
Теремкәйдә төлке яши.

Теремкәйгә, җырлый-җырлый, аю килә.

**Аю** (*ишек шакый*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан.** Мин – тычкан.
**Куян.** Мин – куян.
**Бүре.** Мин – бүре.
**Төлке.** Мин – төлке.
**Бергә.** Син кем?
**Аю.** Мин – аю. Мин – зур, матур аю.
**Бергә.** Әйдә, кил монда.
**Аю** (*керә*). Мин җырлыйм. Әйдәгез, җырлыйбыз.

Музыка. Балалар белән бергә җырлыйлар.

Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм. | *2 тапкыр*
Мин матур җырлыйм, җырлыйм. |

| | |
|---|---|
| Лə-лə-лə-лə, лə-лə-лə-лə,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>**Тəрбияче.**<br>Терем-терем, теремкəй,<br>Зур түгел, кечкенə.<br>Теремкəйдə тычкан яши, чи-чи-чи.<br>**Тычкан.** Мин – тычкан.<br>**Тəрбияче.**Теремкəйдə куян яши.<br>**Куян.** Мин – куян.<br>**Тəрбияче.** Теремкəйдə бүре яши.<br>**Бүре.** Мин – бүре.<br>**Тəрбияче.** Теремкəйдə төлке яши.<br>**Төлке.** Мин –төлке.<br>**Тəрбияче.** Теремкəйдə аю яши.<br>**Аю.** Мин – аю.<br>**Тəрбияче.** Алар бик дус.<br>Күңелле музыка яңгырый. Барысы бергə бииләр. | |
| 53 нче тема: **«ТЕРЕМКӘЙ» ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ** | |
| **Эшчəнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| **«Теремкəй» əкиятен сəхнəлəштерү**<br>Əкиятне тəрбияче ярдəмендə балалар күрсəтə. Балаларга рольлəр (тычкан, куян, бүре төлке, аю) бүлеп бирелə, алар битлеклəр киялəр һəм «урманга» килəлəр. Калган балалар, кулга-кул тотынышып, түгəрəккə басалар, теремкəй ясыйлар.<br>**Балалар** (*түгəрəктə əйлəнеп йөреп*).<br>Терем-терем, теремкəй,<br>Зур түгел. (*Кулларын өскə күтəреп күрсəтəлəр.*)<br>Кечкенə. (*Чүгəлилəр.*)<br>Тук-тук-тук! (*Уч төплəренə бармак очлары белəн суккалап.*) Теремкəйдə кем яши?<br>Юк, яшəми. (*Кулларын җəеп.*)<br>Теремкəйгə тычкан килə. (*Маңгайларына кулларын куеп, тирə-якны карыйлар.*)<br>Тычкан битлеге кигəн б а л а (тычкан образына кереп) теремкəйгə килə.<br>**Тычкан** (*ишекне шакып*). Тук-тук-тук! Теремкəйдə кем яши? | Тычкан, куян, бүре, төлке, аю битлеклəре |

| | |
|---|---|
| **Балалар.** Юк, яшәми. Әйдә, кер.<br>**Тычкан.** Мин яшим. (*Кереп китә.*)<br>**Балалар** (*түгәрәктә әйләнеп йөреп*).<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, (*Кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр.*)<br>Кечкенә. (*Чүгәлиләр.*)<br>Тук-тук-тук! (*Уч төпләренә бармак очлары белән суккалап.*) Теремкәйдә кем яши?<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйгә куян килә. (*Маңгайларына кулларын куеп, тирә-якны карыйлар.*)<br><br>Куян битлеге кигән бала (куян булып сикергәләп) теремкәйгә килә.<br><br>**Куян** (*ишекне шакып*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>**Тычкан.** Мин – тычкан. Син кем?<br>**Куян.** Мин – куян. Матур куян. Мин сикерәм. Әйдәгез, сикерәбез.<br><br>Балалар белән бергә сикерәләр.<br><br>**Тычкан.** Куян, әйдә, кил монда.<br><br>Куян кереп китә.<br><br>**Балалар** (*түгәрәктә әйләнеп йөреп*).<br>Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, (*Кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр.*)<br>Кечкенә. (*Чүгәлиләр.*)<br>Тук-тук-тук! *(Уч төпләренә бармак очлары белән суккалап.)* Теремкәйдә кем яши?<br>Теремкәйдә тычкан яши,<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйгә бүре килә. (*Маңгайларына кулларын куеп, тирә-якны карыйлар.*)<br><br>Бүре битлеге кигән бала (бүре образына кереп) теремкәйгә килә.<br><br>**Бүре** (*ишекне шакып*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>**Тычкан.** Мин – тычкан.<br>**Куян.** Мин – куян.<br>**Бергә.** Син кем?<br>**Бүре.** Мин – бүре. Мин – зур, кара бүре. Мин йөгерәм. Әйдәгез, йөгерәбез. | |

Балалар белән бергә йөгерәләр.

**Бергә.** Бүре, әйдә, кил монда.

Бүре кереп китә.

**Балалар** (*түгәрәктә әйләнеп йөреп*).
Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, (*Кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр.*)
Кечкенә. (*Чүгәлиләр.*)
Тук-тук-тук! (*Уч төпләренә бармак очлары белән суккалап.*) Теремкәйдә кем яши?
Теремкәйдә тычкан яши,
Теремкәйдә куян яши,
Теремкәйдә бүре яши.
Теремкәйгә төлке килә. (*Маңгайларына кулларын куеп, тирә-якны карыйлар.*)

Төлке битлеге кигән бала (төлке образына кереп) теремкәйгә килә.

**Төлке** (*ишекне шакып*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?
**Тычкан.** Мин – тычкан.
**Куян.** Мин – куян.
**Бүре.** Мин – бүре.
**Бергә.** Син кем?
**Төлке.** Мин – төлке. Мин – зур, матур төлке. Мин бииm. Әйдәгез, биибез.

Музыка. Балалар белән бергә бииләр.

**Бергә.** Төлке, әйдә, кил монда.

Төлке кереп китә.

**Балалар** (*түгәрәктә әйләнеп йөреп*).
Терем-терем, теремкәй,
Зур түгел, (*Кулларын өскә күтәреп күрсәтәләр.*)
Кечкенә. (*Чүгәлиләр.*)
Тук-тук-тук! (*Уч төпләренә бармак очлары белән суккалап.*) Теремкәйдә кем яши?
Теремкәйдә тычкан яши,
Теремкәйдә куян яши,
Теремкәйдә бүре яши,
Теремкәйдә төлке яши.
Теремкәйгә аю килә. *(Маңгайларына кулларын куеп, тирә-якны карыйлар.*)

Аю битлеге кигән бала (аю образына кереп) теремкәйгә килә.

| | |
|---|---|
| **Аю** (*ишекне шакып*). Тук-тук-тук! Теремкәйдә кем яши?<br>**Тычкан.** Мин – тычкан.<br>**Куян.** Мин – куян.<br>**Бүре.** Мин – бүре.<br>**Төлке.** Мин – төлке.<br>**Бергә.** Син кем?<br>**Аю.** Мин – аю. Мин – зур, матур аю. Мин җырлыйм. Әйдәгез, җырлыйбыз.<br>Музыка. Балалар белән бергә җырлыйлар.<br>Мин җырлыйм, җырлыйм, җырлыйм.<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм. \| *2 тапкыр*<br>Лә-лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә,<br>Мин матур җырлыйм, җырлыйм.<br>**Тәрбияче.** Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>**Тычкан.** Мин – тычкан.<br>**Тәрбияче.** Теремкәйдә куян яши.<br>**Куян.** Мин – куян.<br>**Тәрбияче.** Теремкәйдә бүре яши.<br>**Бүре.** Мин – бүре.<br>**Тәрбияче.** Теремкәйдә төлке яши.<br>**Төлке.** Мин – төлке.<br>**Тәрбияче.** Теремкәйдә аю яши.<br>**Аю.** Мин – аю.<br>**Тәрбияче.** Алар бик дус.<br>Күңелле музыкага бергәләп бииләр. | |

## 54 нче тема: **«ТЕРЕМКӘЙ»**

МУЛЬТФИЛЬМ: «ТЕРЕМКӘЙ»

## 55 нче тема: **ӨСТӘЛ ТЕАТРЫ: «КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?»**

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
|---|---|
| **Өстәл театры: «Кем нәрсә ярата?»**<br>*Аудио (72 нче кисәк)*<br>**Тәрбияче.** Я вам расскажу сказку «Кто что любит? – Кем нәрсә ярата?», а вы мне помогите. | Өй макеты.<br>Өстәл театры атрибутлары: |

| | |
|---|---|
| *Персонажлар:* Эт, песи, әтәч, кәҗә.<br>*Күренеш:* Өй макеты. Анда әтәч, эт, песи, кәҗә яши. Ишегалдында яшел чирәм үсә. Өйдән ерак түгел эт оясы. Иртә. Кошлар сайраган тавышлар ишетелә. Киртәгә әтәч сикереп менә, канат кагып кычкыра.<br><br>**Әтәч.** Кикри-күк, кикри-күк. (*Киртәдән сикереп төшә, чирәм чүпли башлый.*) Ко-ко-ко.<br><br>Өйдән әкрен генә, ялкау атлап, песи чыга, киерелә.<br><br>**Песи.** Мияу-мияу-мияу. (*Әтәчкә карап.*) Хәерле көн, әтәч!<br>**Әтәч.** Хәерле көн, песи!<br>**Песи.** Хәлләр ничек, әтәч?<br>**Әтәч.** Әйбәт. Рәхмәт. Ә синең хәлләрең ничек?<br><br>Шулвакыт эт йөгереп чыга.<br><br>**Эт.** Һау-һау-һау. Исәнме, әтәч! Исәнме, песи!<br>**Әтәч, песи.** Исәнме, эт!<br>**Эт.** Кәҗә кая?<br>**Әтәч, песи.** Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br>**Эт.** Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>**Песи.** Мин сөт яратам. Сөт тәмле. Әтәч, син нәрсә яратасың?<br>**Әтәч.** Мин ботка яратам. Ботка тәмле.<br><br>Кәҗә килә. Кәрзиндә кәбестә, сөт, ипи, ботка.<br><br>**Кәҗә.** Исәнмесез! Хәерле көн! Хәлләр ничек?<br>**Бергә.** Әйбәт.<br>**Кәҗә.** Мин кәбестә ашыйм. Кәбестә бик тәмле. Акбай, мә кәбестә, аша. Кәбестә тәмле.<br>**Акбай.** Юк, мин ипи яратам. Син кәбестә аша. Ипи кирәк.<br>**Кәҗә.** Мә ипи, аша.<br>**Акбай.** Рәхмәт. Ипи тәмле.<br>**Песи.** Мин сөт яратам. Сөт юк.<br>**Кәҗә.** Сөт бар. Песи, кил монда. Сөт ал, эч.<br>**Песи** (*сөт эчә*). Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Әтәч, кил монда, сөт эч.<br>**Әтәч.** Юк, мин сөт яратмыйм. Мин ботка яратам. Ботка юк.<br>**Кәҗә.** Кәрзиндә ботка бар. Әтәч, кил монда. Мә ботка, аша.<br>**Әтәч.** Зур рәхмәт. Ботка бик тәмле. Мә, кәҗә, ботка аша. | эт, песи, әтәч, кәҗә.<br>Аудиоязма № 72 |

| | |
|---|---|
| **Кәҗә.** Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.<br>**Әтәч.** Юк, ботка тәмле.<br>**Песи.** Юк, сөт тәмле.<br>**Эт.** Юк, ипи тәмле.<br>Кыз, бәхәсләшкәннәрен ишетеп, алар янына килә.<br>**Кыз.** Ипи тәмле, сөт тәмле, ботка тәмле, кәбестә тәмле. Мин ипи, ботка, кәбестә яратам.<br>Бергәләшеп җырлыйлар, бииләр.<br>Ипи тәмле, Ботка тәмле,<br>Сөт тәмле, Кәбестә тәмле. | |

## 56нчы тема: «КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?» ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ

| Эшчәнлек барышы | Җиһазлау |
|---|---|
| **«Кем нәрсә ярата?» әкиятен сәхнәләштерү**<br>Әкиятне тәрбияче ярдәмендә балалар күрсәтә. Балаларга рольләр (әтәч, эт, песи, кәҗә) бүленеп бирелә, алар битлекләр кияләр.<br>*Персонажлар:* Эт, песи, әтәч, кәҗә.<br>*Күренеш:* Өй макеты. Анда әтәч, эт, песи, кәҗә яши. Ишегалдында яшел чирәм үсә. Өйдән ерак түгел эт оясы. Иртә. Кошлар сайраган тавышлар ишетелә. Киртәгә әтәч сикереп менә, канат кагып кычкыра.<br>**Әтәч.** Кикри-күк, кикри-күк. (*Киртәдән сикереп төшә, чирәм чүпли башлый.*) Ко-ко-ко.<br>Өйдән әкрен генә, ялкау атлап, песи чыга, киерелә.<br>**Песи.** Мияу-мияу-мияу. (*Әтәчкә карап.*) Хәерле көн, әтәч!<br>**Әтәч.** Хәерле көн, песи!<br>**Песи.** Хәлләр ничек, әтәч?<br>**Әтәч.** Әйбәт. Рәхмәт. Ә синең хәлләрең ничек?<br>Шулвакыт эт йөгереп чыга.<br>**Эт.** Һау-һау-һау. Исәнме, әтәч! Исәнме, песи!<br>**Әтәч, песи**. Исәнме, эт!<br>**Эт.** Кәҗә кая?<br>**Әтәч, песи**. Әнә кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата.<br>**Эт.** Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>**Песи.** Мин сөт яратам. Сөт тәмле. Әтәч, син нәрсә яратасың?<br>**Әтәч.** Мин ботка яратам. Ботка тәмле. | Өй макеты. Эт, песи, әтәч, кәҗә битлекләре. Аудиоязма № 73 |

| | |
|---|---|
| К ә җ ә килә. Кәрзиндә кәбестә, сөт, ипи, ботка.<br>**Кәҗә.** Исәнмесез! Хәерле көн! Хәлләр ничек?<br>**Бергә.** Әйбәт.<br>**Кәҗә.** Мин кәбестә ашыйм. Кәбестә бик тәмле. Акбай, мә кәбестә, аша. Кәбестә тәмле.<br>**Акбай.** Юк, мин ипи яратам. Син кәбестә аша. Ипи кирәк.<br>**Кәҗә.** Мә ипи, аша.<br>**Акбай.** Рәхмәт. Ипи тәмле.<br>**Песи.** Мин сөт яратам. Сөт юк.<br>**Кәҗә.** Сөт бар. Песи, кил монда. Сөт ал, эч.<br>**Песи** (*сөт эчә*). Мин сөт эчәм. Сөт тәмле. Әтәч, кил монда, сөт эч.<br>**Әтәч.** Юк, мин сөт яратмыйм. Мин ботка яратам. Ботка юк.<br>**Кәҗә.** Кәрзиндә ботка бар. Әтәч, кил монда. Мә ботка, аша.<br>**Әтәч.** Зур рәхмәт. Ботка бик тәмле. Мә, кәҗә, ботка аша.<br>**Кәҗә.** Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.<br>**Әтәч.** Юк, ботка тәмле.<br>**Песи.** Юк, сөт тәмле.<br>**Эт.** Юк, ипи тәмле.<br>К ы з, бәхәсләшкәннәрен ишетеп, алар янына килә.<br>**Кыз.** Ипи тәмле, сөт тәмле, ботка тәмле, кәбестә тәмле. Мин ипи, ботка, кәбестә яратам.<br>Бергәләшеп җырлыйлар, бииләр.<br>*Аудио (73 нче кисәк)*<br>Ипи тәмле, Ботка тәмле,<br>Сөт тәмле, Кәбестә тәмле. | |
| 57 н ч е т е м а: **КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?**<br>МУЛЬТФИЛЬМ: «КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?» | |
| 58 н ч е т е м а: **БЕЛЕМ ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ**<br>**Актив сүзләр *(сөйләм үрнәге)*:**<br>*үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләре кулланыла* | |
| **Эшчәнлек барышы** | **Җиһазлау** |
| Зур матур китап. Һәр битендә темалар буенча сюжетлы һәм аерым рәсемнәр. | |

| | |
|---|---|
| *Аудио (74 нче кисәк)*<br>– Какая красивая книга! Ребята, эта книга волшебная. В каждой её страничке таится секрет, волшебство. Давайте посмотрим вместе, какая тайна спрятана в этой волшебной книге.<br>Тәрбияче китапның беренче битен ача. Беренче биттә «Гаилә», «Ашамлыклар» темасына караган рәсемнәр.<br>**1. Үстерелешле уен: «Бу кем? Нәрсә? Нинди? Нишли?»**<br>1) Балаларга рольләр бүленеп бирелә, алар битлекләр кияләр, үзләре турында рәсемнәргә һәм муляжларга карап сөйлиләр.<br>**Әни.** Мин – әни. Мин – матур, әйбәт әни. Мин ипи яратам. (*Ипигә күрсәтеп яисә ипине алып.*) Ипи тәмле.<br>**Әти.** Мин – әти. Мин – зур, әйбәт әти. Мин аш яратам. Аш тәмле.<br>Шул үрнәктә һәр бала сөйли.<br>2) Һәр бала, рәсемнәргә карап, тәрбияче (Акбай, Мияу ) үрнәгендә үзе теләгән гаилә әгъзасы, ашамлык турында кыска хикәя төзеп сөйли.<br>*Аудио (75 нче кисәк)*<br>**Акбай.** Бу – әни. Әни матур, әйбәт, зур. Бу – ипи. Әни ипи ашый. Ипи тәмле. Әни ипи ярата.<br>**Мияу.** Бу – әти. Әти зур, матур, әйбәт. Бу – сөт. Әти сөт эчә. Сөт тәмле. Әти сөт ярата.<br>**2. Уен ситуациясе. Үстерелешле диалог: «Әйдәгез, танышабыз!»**<br>Китапның икенче битендә «Җәнлекләр», «Йорт кошлары» темасына караган рәсемнәр. Балалар рольләргә бүленәләр, үзләре өйрәнгән лексиканы кулланып, диалог төзиләр; *нишлисең*? соравына җавап биргән фигыльләрне кулланалар. Җәнлекләр, кошлар очрашалар. Төлке белән керпе.<br>1) **Төлке** (*биеп торган керпе янына килә*). Исәнме, керпе!<br>**Керпе.** Исәнме, төлке! Хәлләр ничек?<br>**Төлке.** Әйбәт. Керпе, син нишлисең?<br>**Керпе.** Мин биим. Төлке, кил, бие. (*Төлкене биергә чакыра. Төлке бии.*)<br>**Төлке.** Мин биим. (*Икәү бииләр, бии-бии китәләр.*)<br>Куян белән тычкан. | Һәр битендә үткән темалар буенча сюжетлы һәм аерым рәсемнәр ясалган зур китап; әни, әти, бабай, әби, кыз, малай, эт, песи, төлке, керпе, куян, тычкан битлекләре. Ашамлык муляжлары; уенчыклар, савыт-сабалар, йорт җиһазлары. Балалар санынча яшелчә, җиләк-җимеш рәсемнәре. Эш дәфтәре. Аудиоязма № 74–76 |

<table>
<tr>
<td>2) Куян. Хәерле көн, тычкан!<br>Тычкан. Хәерле көн, куян!<br>Куян. Тычкан, мин зур. Син нинди?<br>Тычкан. Ә мин кечкенә. Куян, син нишлисең?<br>Куян. Мин сикерәм. (Сикергечтән (скакалка) сикерә.) Син нишлисең?<br>Тычкан. Мин җырлыйм. (Җырлый.) Куян, кил, җырла. (Куянны җырларга чакыра.)<br>Икәү җырлый-җырлый китәләр.<br>Аудио (76 нчы кисәк)<br>Мин – куян, мин – куян,<br>Зур куян, матур куян.<br>Мин – тычкан, мин – тычкан,<br>Кечкенә, матур тычкан.<br>Диалог шул үрнәктә башка балалар белән дәвам итә.<br>3. Уен: «Компот, салат ясыйбыз»<br>Китапның өченче бите ачыла. Анда «Яшелчәләр», «Җиләк-җимешләр» темасына караган рәсемнәр.<br>4. Күнегү: «Нәрсә кирәк? Бел!»<br>Балалар компот һәм салат өчен кирәкле яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне әйтәләр. Рәсемдә кәстрүл һәм салат савыты. Балалар яшелчә, җиләк-җимеш исемнәрен әйтәләр, кирәкле урынга урнаштыра баралар. Бу күнегүне дәфтәрдә эшләргә дә мөмкин.<br>5. Дәфтәрдә эш: 20 нче бирем. «Помоги маме»<br>6. Ситуатив күнегү: «Уенчыклар качканнар» («Нәрсә юк?» яисә «Дөрес урнаштыр»)<br>Китапның дүртенче битендә «Уенчык», «Савыт-саба», «Йорт җиһазлары» темаларына караган рәсемнәр. Тәрбиячененең өстәлендә төрлечә урнаштырылган уенчык савыт-сабалар, йорт җиһазлары. Балалар аларны дөрес итеп классификацияләргә тиеш.</td>
<td></td>
</tr>
<tr>
<td colspan="2">59 нчы тема: «МОГҖИЗАЛАР КЫРЫ» УЕНЫ</td>
</tr>
<tr>
<td>Эшчәнлек барышы</td>
<td>Җиһазлау</td>
</tr>
<tr>
<td>Уен ситуациясе: «Серле хат»<br>Тәрбияче. Ребята, нам прислали электронное письмо. Письмо от Королевы выпускного бала. Давайте его послушаем.</td>
<td>«Могҗизалар кыры» уенына кирәкле җиһазлар,</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| *Аудио (77 нче кисәк)*<br>«Дорогие ребята! Я вас приглашаю на выпускной бал, который состоится в моём королевстве «Знание – Белем». Но для этого вы должны выполнить все мои задания. Они в этом волшебном сундучке. Если все задания выполните успешно, вы непременно попадёте в моё королевство, где говорят на татарском языке. Желаю вам удачи и с нетерпением жду вас у себя».<br><br>Өстәлдә һәр тема буенча төрле типтагы биремнәр (сюжетлы рәсемнәр, пиктограммалар) салынган конвертлар. Бала өстәлдән бер конвертны ала, тәрбиячегә бирә. Тәрбияче биремне укый, бала үти. Биремнәрне, өйрәнгән лексиканы, материалны кулланып, ковролинда, магнитлы тактада, интерактив тактада, дәфтәрдә дә әзерләргә була. Шулай ук күмәк һәм аерым командаларга бүленеп үтәргә дә ярый. Биремнәр арасында музыкаль тәнәфес ясала.<br><br>*Аудио (78 нче кисәк)*<br>Ребята, молодцы! Вы выполнили все мои задания. Добро пожаловать в моё королевство «Знание – Белем», где говорят на татарском языке. Желаю вам удачи! | биремнәр.<br>Аудиоязма<br>№ 77, 78 |
| 60 нчы тема: **БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР** | |
| **Бакчада чыгарылыш кичәсе: «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар»** | |

# ДИАГНОСТИКА

Түбәндәге биремнәрне балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләгәндә кулланырга була. Тикшерү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5–10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, тикшерүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда, тәрбияче, елмаеп, кирәк булса, җавапны дөресли, әгәр бала әйтә алмый торса, аңа ярдәм итә.

Тикшерү нәтиҗәләре таблицага языла. Нәтиҗәгә карап, тәрбияче, һәр бала белән эшләү өчен, бурычлар билгели.

**Мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларның татар телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү («Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча)**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча 5–6 рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (*исәнме, исәнмесез, сау бул, сау булыгыз, рәхмәт, зур рәхмәт, хәерле көн, хәлләр ничек? әйбәт*) | Боера белү (*кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла*) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү (*нәрсә кирәк? нинди? ничә? син кем? бу кем? бу нәрсә? нишли? кая барасың?*) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкяр итү, раслау) |
| 1 | Коля ... | | | | | |
| 2 | Оля ... | | | | | |
| 3 | ... | | | | | |
| 4 | ... | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне бәяләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

## ЭЧТӘЛЕК

«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проектының тематик планы (мәктәпкә әзерлек төркеме)................................... 3
Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар ........................ 7
Диагностика ........................................................................ 71

Учебное издание

**Зарипова** Зифа Мирхатовна и др.

**ГОВОРИМ ПО-ТАТАРСКИ**
**(обучение татарскому языку детей 6–7 лет)**

Методическое пособие

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском и русском языках

Уку-укыту басмасы

**Зарипова** Зифа Мирхәт кызы һ.б.

**ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ**
**(6–7 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү)**

Методик кулланма

Мөхәррире *В. Г. Гомәрова*
Тышлык рәссамы *Ю. А. Щетинкина*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректоры *Г. Р. Ногманова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.11.2012. Форматы $60\times90\,^1/_{16}$.
Шартлы басма табагы 4,5. Тиражы 3100 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail:info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.